МУНИЦИПАЛЬНОЕ АВТОНОМНОЕ ДОШКОЛЬНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ГОРОДА НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ «ЦЕНТР РАЗВИТИЯ РЕБЕНКА – ДЕТСКИЙ САД № 83 «ФЕЯ»
423832, Республика Татарстан, город Набережные Челны, Бульвар Касимова, д. 7

ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕНЕҢ МУНИЦИПАЛЬ АВТОНОМИЯЛЕ МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ «ТЫЛСЫМЧЫ КЫЗ» 83 НЧЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ – БАЛАНЫ ҮСТЕРҮ ҮЗӘГЕ»
423832, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Касимов урамы, 7 йорт

Телефон/факс +7 (8552)-34-91-71, +7 (8552)-34-68-05, e-mail: sad083@inbox.ru

---

«СОГЛАСОВАНО»
Ст. медсестра ______ Шайхиева С.Ф.
«24» августа 2022г.
Ст. воспитатель ______ Шляхтина Ю.А.
«24» августа 2022г.

«УТВЕРЖДАЮ»
Заведующий МАДОУ
«Центр развития ребенка – детский сад №83 «Фея»
__________ Юлчурина Ю.В.
«24» августа 2022г .

Введено в действие
приказом заведующего
от 24.08.2022 № 456

Рассмотрено и утверждено
на педагогическом совете
от 24.08.2022
Протокол № 1

# ЭШ ПРОГРАММАСЫ

## беренче кече төркем (2 яшьтән 3 яшькә кадәр) № 2

## 2022/2023 уку елы өчен

**Тәрбияче :**
**Шигапова Л.Р**
**Сахапова А.М.**

Яр Чаллы шәһәре
2022ел

Яр Чаллы шәһәре
2022ел

# Эчтәлек


**1. Максатчан бүлек.**

1.1.Аңлатмалы язу.

1.1.1. Программаны тормышка ашыру максаты һәм бурычлары

1.1.2. 3- 4 яшьлек балаларның шәхси һәм яшь үзенчәлекләре

1.1.3. Төркем эшчәнлегенең төп юнәлеше

1.1.4. Программаның принциплары

1.2. Максатчан юнәлешләр

**2. Эчтәлек бүлеге**

2.1.Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге

2.1.1.Социаль-коммуникатив үсеш өлкәсе

2.1.2.Танып белү үсеш өлкәсе

2.1.3.Сөйләм үстерү үсеш өлкәсе

2.1.4.Нәфасәти үсеш өлкәсе

2.1.5.Физик үсеш өлкәсе

2.2. Гаилә белән үзара аралашу

**3. Оештыру бүлеге.**

3.1.Өлкәннәр төркемендә көндәлек режим

3.2.Үстерешле предметлы тирәлекнең үзенчәлекләре

3.3.Материаль-техник һәм методик кулланма

3.4. Көндәлек режим

3.5. Турыдан- туры белем бирү эшчәнлегенең расписаниесе

3.6. Традицион вакыйгалар, бәйрәмнәр, чаралар

**Программа паспорты**

- Федеральный закон от 29.12.2012 № 273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации» (с изменениями от 14.07.2022г.).
- Федеральный закон от 03.08.2018 г. №317 –ФЗ «О внесении изменений в статьи 11 и 14 Федеральный закон «Об образовании в Российской Федерации».
- Федеральный государственный образовательный стандарт дошкольного образования (Утвержден приказом Министерства образования и науки Российской Федерации от 17 октября 2013 г. N 1155).
- Комментарии к ФГОС дошкольного образования Минобрнауки России Департамента общего образования от 28 февраля 2014 года № 08-249.
- Приказ Министерства просвещения РФ от 31 июля 2020 г. № 373 «Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – образовательным программам дошкольного образования».
- Постановление Правительства РФ от 15 сентября 2020г. №1441 «Об утверждении Правил оказания платных образовательных услуг».
- СП 2.4.3648 – 20 «Санитарно – эпидемиологические требования к организациям воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодежи», утвержденный Постановлением Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 28.09.2020 №28 об утверждении санитарных правил. Зарегистрирован в Министерстве юстиции РФ от 18.12.2020 №61573.
- Постановление Главного государственного санитарного врача РФ от 28.01.2021 №2 «Об утверждении санитарных правил и норм СанПиН 1.2.3685-21 «Гигиенические нормативы и требования к обеспечению безопасности и (или)безвредности для человека факторов среды, обитания» (вместе с СанПиН 1.2.3685-21 «Санитарные правила и нормы..»).
- Постановление Главного государственного санитарного врача РФ от 27.10.2020 г. №32 «Об утверждении санитарно-эпидемиологических правил и норм СанПиН 2.3/2.4.3590-20» Санитарно-эпидиомологические требования к организации общественного питания населения.
- Санитарно-эпидемиологические правила СП 3.1/2.4.3598-20 «Санитарно-эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации работы образовательных организаций и других объектов социально инфраструктуры для детей и молодежи в условиях распространения новой коронавирусной инфекции (COVID-19)», утвержденный постановлением Главного государственного санитарного врача РФ от 30.06.2020 №16, с изменениями от 24.03.2021 г. (Постановление Главного государственного санитарного врача РФ №10 «О внесение изменений).
- Закон Республики Татарстан «Об образовании» от 22.07.2013г № 68-ЗРТ (принят Государственным Советом 28.06.2013 г).
- Закон Республики Татарстан «О государственных языках Республики Татарстан и других Языках в Республики Татарстан» (изменения и дополнения от 28.07.2004 г № 44-ЗРТ; от 12.06.2014 г № 53-ЗРТ).
- Устав ДОУ;
- Основная образовательная программа ДОУ;
- Рабочая программа воспитания ДОУ

## Кереш.

“Об образовании в Российском Федерации” Федераль канунына нигезләнеп, Россиядә мәктәпкәчә белем бирү гомуми белем бирүнең беренче дәрәҗәдәге статусын алды. Белем бирү программаларын тормышка ашырганда мәктәпкәчә белем бирү ФДББС “Об утверждении федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования» (Приказ Министерства образования и науки Российской Федерации № 1155 от 17 октября 2013 года), нигезендә җайга салына. Аның төп бурычы- мәктәпкәчә яшьтәге балаларның тулы кыйммәтле яшәеше өчен уңайлы шартлар тудыру, шәхес культурасының нигезле җирлеген формалаштыру. Программаны төзегәндә белем бирү үсешендә хәзерге заман халыкара тенденцияләр исәпкә алынды:

- балада әйләнә-тирәгә яңа караш формалаштыру;

- практикада белем бирүнең төп юнәлешләрен (экологик, экономик, социаль) тормышка ашыру;

- эшчәнлектә балаларның шәхси тәҗрибәләрен (көнкүреш, культура, социаль, әхлакый) актив куллану;

- балалар инициативасын, белемнә омтылышын, мөстәкыйльлеген үстерү;

- белем бирү процессын нәтиҗәле итү өчен төрле эшчәнлекне берләштерү (интегральләштерү)

- балаларның уенга, куркынычсызлыкка, уңайлы әйләнә-тирәгә хокукын саклау;

-сыйфатлы белем алуга мөмкинлек тудыру;

- балаларны социумга актив кертү.

## 1. Максатчан бүлек.

1.1. **Аңлатмалы язу.**

Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы (алга таба Программа) «Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программа- сы структурасына Федераль дәүләт таләпләре»нә (РФ Мәга- риф һәм фән министрлыгының 23.11.2009 елда 655 нче карары нигезендә расланган) нигезләнеп төзелде. Программада 3 яшьтән 7 яшькә кадәр булган балаларга төбәкнең климатик, милли-мәдәни, демографик, социаль-эко- номик шартларын исәпкә алып, белем бирү процессында кат- нашучылар тарафыннан формалаштырыла торган белем бирү эчтәлеге чагылдырыла. Программа нигезендә мәктәпкәчә белем бирү учреждени- есе мөстәкыйль рәвештә мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасының вариатив өлешен эшли, раслый һәм тормыш- ка ашыра; шуның белән балаларның физик, социаль һәм акыл үсеше хокукларын (Бала хокуклары турындагы Конвенция, 1989), барлык балалар өчен мәктәпкәчә баскычтан башлан- гыч мәктәпнең беренче сыйныфына укырга күчкәндә тигез мөмкинлекләрен тәэмин итә. Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш законча- лыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фун- даменталь тикшеренүләргә, мәктәпкәчә белем бирү өлкәсен- дә әйдәп баручы белгечләр хезмәтләрендә (Л. С. Высотский, П. Я. Гальперин, В. В. Давыдов, А. В. Запорожец, А. Н.

Леонтьев, С. Л. Рубенштейн һ. б.) чагылыш тапкан фәнни тикшеренүләргә, гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген көйләп торучы башка норматив-хокукый актлар положениеләренә нигезләнә. Программа мәктәпкәчә яшьтәге балалар үсеше пробле- масына мәдәни-тарихи якын килүгә туры китереп эшләнде, анда фәнни нигезләнү һәм гамәли кулланыш принциплары берләштерелде. Программаны гамәлгә ашыру белем бирү про- цессын төзүнең комплекслы тематик принцибына, мәктәкэчэ белем бирүнең бөтенлек һәм интеграция принципларына нигезләнде, балаларның яшьләренә туры килгән эш формала- рын һәм эшчәнлек төрләрен исәпкә алып төзелде. Программа белем бирү процессын эшкә ашыруны өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлеген, балаларның мөстәкыйль эшчәнлеген үз эченә алган ике төп оештыручы модель ярдәмендә тәэмин итә; 6 яшьтән 7 яшькә кадәр булган бала- ларга белем биргәндә яшь үзенчәлекләренә тәңгәл килерлек укыту моделен күздә тота, мәктәпкәчә гомуми белем бирүнең үрнәк программалары белән бәйләнешне тәэмин итә. Программа балада һәрьяклы (физик, шәхси, танып белү, рухи, эстетик) үсешне арттыруга юнәлтелә һәм милли культура, туган якны, туган (татар, рус) телне өйрәнү аша аның баетылуын күздә тота. «Милли культураны, үз халкыңның рухи байлыгын өйрәнү, аны шушы җирдә яшәгән башка халыклар культурасы белән баету, баланың культурага булган билгеләмәсе киләчәктә аңа бөтендөнья культурасын аңларга ярдәм итәчәк. Бары тик үз халкының культурасына булган шундый киң караш, аны зуррак масштабтагы культура процесслары контекстларында кабул итү генә иҗади шәхес формалашуга һәм үсешенә нигез булып тора- чак, ул үз чиратында милли культураны пассив күзәтергә генә түгел, ә аңа шәхсән үз өлешен кертергә, культура барлыкка килү процессында катнаширга мөмкинлек бирәчәк» (Ф. Ф. Харисов). Программада психилого-педагогик эшнең бурычлары дүрт юнәлеш буенча бүленеп бирелгән: физик, социаль-шәхси, та- нып белү-сөйләм, нәфис-нәфасәти үсеш юнәлешләре.

### 1.1.1. Программаның максаты һәм бурычлары.

**Максат:** әйләнә-тирә белән танышуда нигез буларак, яшь үзенчәлеге буенча бурычлар һәм проблемаларны чишү, башка балалар һәм өлкәннәр белән актиив аралашу процессында балаларда культура тәҗрибәсе туплау, өзлексез белем алуга һәм мөстәкыйльлеккә әзерлек булдыру.

**Бурычлар:**

- милләтенең, теленең, социаль чыгышының нинди булуына карамастан, һәр балада аны яратуларына ышаныч, тормыш өчен җайлы шартлар тудыру;
- шәхси һәм яшь һәм үзенчәлеге буенча балаларның һәрьяклы үсеше өчен уңайлы шартлар тудыру;
- балада социаль- әхлакый, физик, интеллектуаль, эстетик сыйфатлар үстерү;
- кеше эшчәнлегенең төп формаларында үзен-үзе ачу һәм иҗат итү сәләтен, ихтыяҗын формалаштыру, дөнья белән берлектә үзен-үзе танып белү, аның белән әңгәмә алып баруга әзерлек;
- баланың гомуми шәхси культурасын, шул исәптән сәламәт яшәү рәвешенең кыйммәтен, белем алу эшчәнлегендә алшартны, инициативасын, мөстәкыйльлеген һәм җаваплылыгын, актив тормыш позициясен формалаштыру;
- һәр баланың сәләтен һәм иҗади потенциалын үстерү;
- гуманлык кыйммәтләре һәм идеалы, ирекле кешенең хокуклары нигезендәбаланың башка балалар, өлкәннәр һәм әйләнә-тирә белән үзара йогынтысын оештыру;
- балаларда Ватанга патриотик хис һәм мәхәббәт, рухи-әхлакый һәм социокультура кыйммәтләре нигезендә аның уңышлары өчен горурлану хисе тәрбияләү;

- шәхси һәм яшь үзенчәлеге, психо-физиологик үзенчәлекләр буенча социокультура мохите формалаштыру;
- гаиләнең һәм җәмгыятьнең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләре нигезендә гаиләнең һәм балалар бакчасының тәрбияви-сәламәтлек ресурсларын берләштерү;
- гаилә белән үзара партнерлык мөнәсәбәте урнаштыру, психологик һәм педагогик ярдәм күрсәтү, белем һәм тәрбия бирүдә ата-аналарның компетентлылыгын күтәрү;
- балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, максат, бурыч, алымнар, мәктәпкәчә белем бирү, башлангыч гомумбелем бирү дәрәҗәсендә күчүчәнлекне булдыру.

### 1.1.2. 3-4 яшьлек балаларның шәхси һәм яшь үзенчәлекләре

3-4 яшьлек балаларның карашлары акрынлап гаилә чикләрен үтеп чыга башлый. Ситуацияләрдән тыш аралашулар барлыкка килә. Олы кеше аның өчен гаилә әгъзасы гына түгел, ә аерым иҗтимагый функция башкаручыга да әйләнә. Баланың да иҗтимагый функция башкарасы килү теләге аның реаль мөмкинлекләре белән каршылыкка китерә. Бу каршылык мәктәпкәчә яшьтәгеләр эшчәнлегенең төп төре булган уен аша чишелә.

Шартлылык уенның төп үзенчәлеге булып тора: бер төрле предметлар белән эш-хәрәкәтләр аларның башка предметлар белән икенче эш- хәрәкәтләргә каравын күз алдында тота. Уенчыклар һәм аларны алмаштыручы предметлар белән эш- гамәлләр кече яшьтәге балалар уенының төп эчтәлеген тәшкил итә. Кече яшьтәгеләр 1-2 рольле яки гади, җыйнак сюжетлы уеннар белән канәгатьләнәләр. Бу яшьтә кагыйдәле уеннар формалаша гына башлый әле.

Баланың сурәтләү эшчәнлеге аның предмет турында күзаллауларына бәйле. График образлар бик гади, ярлы. Кайбер балаларның сурәтләрендә детальләр җитешми, башкаларның рәсемнәре беркадәр детальләштерелгән булырга мөмкин. Балар инде төсләрне куллана беләләр.

Кул чуклары хәрәкәтен үстерүдә әвәләүнең әһәмияте гаять зур. Кече яшьтәгеләр олылар җитәкчелегендә әвәләп гади предметлар ясарга сәләтле.

Белүебезчә, кисеп ябыштыру кабул итүчәнлекне үстерүгә уңай йогынты ясый. Бу яшьтә балалар аппликациянең иң гади төрләрен эшли алалар.

Кече яшьтәгеләр өчен конструкцияләү эшчәнлеге күрсәтелгән үрнәк буенча һәм үзләре уйлап тапкан гади корылмалар төзүдән гыйбәрәт.

Аларның хәтере һәм игътибарлылыгы үсә. Олылыр тәкъдиме белән балалар 3-4 сүздән һәм 5-6 предмет исемен истә калдыралар, соңрак алар яраткан әсәрләреннән өзекләрне истә калдырырга сәләтле.

Күрсәтмәле- тәэсирле фикер йөртү сәләте үсеше дәвам итә. Шуның белән бергә, ситуацияләр кайбер очракларда уңай нәтиҗәне күздә тоткан максатчан сынаулар нигезендәүзгәртелә. Балалар предметлар арасындагы кайбер яшерен мөнәсәбәтләрне ача алалар.

Бу яшьтә иҗади күзаллау сәләте үсә башлый, уен вакытында бер төрле объектларны башкаларын алыштыручылар сыйфатында кулланалар.

Балалар арасында мөнәсәбәтләр бигрәк тә уен эшчәнлегендә ачык чагыла. Алар күбрәк бергәләшеп түгел, ә янәшә уйнауны өстен күрәләр. Ләкин балалар арасында сайлап алуга корылган мөнәсәбәтләр өстенлек итә. Низаглар күбесенчә уенчыклар аркасында килеп чыга. Баланың төркемдә яшьтәшләре арасында дәрәҗәсе нигездә тәрбияче фикере белән билгеләнә.

Бу яшьтә балалар аңлы рәвештә үз тәртипләре белән идәрә итә белмиләр, күбесенчә баланың тәртибе ситуациягә бәйле. Шуның белән беррәттән, балаларның олылар әйтүе буенча, ниндидер теләкләрен чикләү очраклары да күзәтелә. Үз-үзен бәяләү сыйфаты үсә

башлый, бу күп очракта тәрбияче фикеренә нигезләнгән була. Җенси аерымлыкларның да үсеше күзәтелә. Ул бигрәк тә уенчыклар һәм уен сюжетларын сайлаганда ( кызлар-курчак, малайлар машина сайлый) ачык чагыла. Бала үзенең олылардан аерылып торучы аерым кеше икәнлеген аңлый башлый. Анда *Мин* образы формалаша. Кризис күп кенә тискәре күренешләргә сәбәпче була: негативлык, кирелек, еш кына өлкәннәр белән мөнәсәбәтләрнеңбозылуы һ.б. Кризис берничә айдан 2 елга кадәр сузылырга мөмкин.
Балаларның сәламәтлекләрен ныгыту һәм саклау эшен дәвамитү , организмын даими чыныктыру өчен шартлар тудыру. Гәүдәне төз тотарга өйрәтү, чисталык күнекмәләрен камилләштерү, әйләнә тирәдә ориентлаша белүләрен үстерү, актив хәрәкәт эшчәнлеге, уңай эмоциональ халәт тудыруда булышлык итү.
Өлкәннәрнең һәм яшьтәшләренең тормышы һәм эшчәнлеге, табигать күренешләре белән кызыксыну тәрбияләү. Предметлар һәм күренешләр арасындагы бәйләнешләрне аңларга һәм шуның аша генә нәтиҗәләр чыгара белергә өйрәтү. Балаларның сөйләмен үстерүне дәвам итү: сүзлек запасын баету, җөмләләр төзи белү, сүзләрне дөрес һәм ачык итеп әйтүләренә ирешү.
Әдәби әсәрне ахыргача тыңлый, әкияттә, хикәядә вакыйгаларның ничек үрелеп баруын күзәтә белү сыйфаты тәрбияләү, кечкенә шигырьләрне, юаткычларны укырга һәм хәтерләрендә калдырырга ярдәм итү.
Гади математик күзаллаулар формалаштыру. Тирә- юньдә бер һәм күп санлы предметларны табарга, предмет төркемнәрен чагыштырырга, кайсы предметларның күбрәк икәнен белергә өйрәтү. Көченнән килгәнчәхезмәткә катнашу ,кечерәк кыенлыкларны җиңә белергә белергә өйрәтү.

| **Белем бирү өлкәсе** | **Автор программалары, проект, технологияләр** |
|---|---|
| «Физик үсеш» | Мингазетдинова Г. М., Хакимова Г. М. **«Сәламәт туклану-озын гомерле булу» -** рецензенты Зарипова З. М., Хазратова Ф. В (кандидаты педагогических наук), НГПИ, 2011 г. |
| «Сөйләм үстерү» | Сахабиева А. С. **«Мәктәпкәчә яшьтәге балаларда уен эшчәнлеге аша сөйләм үстерү» -** рецензенты Зарипова З. М., Хазратова Ф. В (кандидаты педагогических наук), НГПИ, 2010 г.<br>Гильмиева С. В. **“Баланың сөйләм телен ачу юллары”-** рецензент Хазратова Ф. В (кандидаты педагогических наук), НГПИ, 2009 г<br>**“Туган телдә сөйләшәбез”** Хазратова Ф.В. , Казан, 2013<br>Закирова К.В. **«Балачак - уйнап-көлеп үсәр чак».**<br>Закирова, Мортазина “Әй уйныйбыз, уйныйбыз” Зарипова “**Үстерешле уеннар**” методическое пособие<br>**Иң матур сүз** (хрестоматия). К.В.Закирова<br>**Гөлбакча** (хрестоматия). Ф.Ю. Юсупов...<br>**Ал кирәк,гөл кирәк** (методик кулланма).<br>**Бала бишеге-гомер ишеге** (җыентык). Ф.Зарипова...<br>К. В. Закирова . Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия “ **Балачак аланы**”.<br>**Раушан көзге** (хрестоматия). Р.Ш.Халикова<br>**Бал бабай.** З.М.Зарипова, И.М. Хәмитов.<br>**Ал кирәк,гөл кирәк** Р. Ягъфәров (**Туган телем- бөек анам теле** (методик кулланма). З.М.Зарипова **Иң матур** |

| | |
|---|---|
| | **сүз** (хрестоматия). |
| «Танып белү үсеше» | Хакимова Г. М**. «Табигатькә сәяхәт»** - рецензенты: Киямова А. Г. (старший преподаватель), Хазратова Ф. В. (кандидат педагогических наук), НГПИ, 2007 г.<br>Хакимова Г. М. **«Табигатьнең сафлыгы – күңелеңнең пакьлеге»**<br>**“Туган телдә сөйләшәбез**” Хазратова Ф.В. , Казан, 2013<br>Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү Программасы “**Мир открытий**» (науч.рук.Л.Г.Петерсон,под общий ред. Л.Г.Петерсон,И.А.Лыковой.)<br>З. М. Зарипова. **Белем һәм тәрбия процессында милли - төбәк компоненты**<br>А. М. Гильфанова, Г.Р. Насырова. Перспективное планирование работы по внедрению национально-регионального компонента в воспитательно-образовательный процесс.<br>Закирова К. В. “**Балалар бакчасында әхлак тәрбиясе”** |
| «Социаль-коммуникатив үсеш» | Мингазетдинова Г. М.**«Киңәшле эш яктылыкка илтә»**-рецензенты: Хазратова Ф. В., Газизова Ф. С. – кандидаты педагогических наук НГПИ, 2008 г.<br>Валеева М. Х., Абдуллина Ф. И. **«Отличный пешеход»** - Рецензент: Адилова Л. Р. , старший преподаватель кафедры Педагогики и Психологии им. З. Т. Шарафутдинова ФГБОУ ВПО «НИСПТР», 2015 г. |
| «Нәфасәти үсеш» | Гиздатуллина А. М. **«Биләүдәге рәссам», “Рисуем и растем”** - рецензенты: Хакимова Х. Х.(кандидат педагогических наук, НГПИ), Шагова Т. Н. (старший преподаватель кафедры ИЗО, НГПИ), 2007г.<br>Исмагулова Л. А. **“Волшебная шкатулка”** - Рецензент: Адилова Л. Р. , старший преподаватель кафедры Педагогики и Психологии им. З. Т. Шарафутдинова ФГБОУ ВПО «НИСПТР», 2014 г.<br>“Сүрәтләү һәм конструкцияләү” Р.М. Зиннатова, Л.Ә. Гараева, А.Г. Зворыкина |

**Региональ компонент:**

- Закирова К.В. «Воспитание и обучение в детском саду». Программа обеспечивает организацию образовательной деятельности в татарских группах.

Задачи воспитания и обучения по НРК: знакомить детей с музыкой, живописью, литературой, искусством народов Поволжья (Россия, Татарстан, Чувашия, Башкортостан, Удмуртия, Марий Эль, Мордовия).Развивать интерес к культурному наследию народов Поволжья.

Воспитывать патриотические чувства, любовь к родному краю, Родине, к родному языку; желание разговаривать на родном языке.

**- Обучение государственным языкам РТ:**

- Хазратова Ф.В. «Туган телдә сөйләшәбез» Методическое пособие для воспитателей татарских групп ДОУ

Төркемнең төп эш юнәлеше экологик тәрбия белән балаларны табигать, сәнгать, нәфасәти эшчәнлекнең төрле төрләре белән таныштыру процессында төрле юллар белән тормышка

ашырыла: төркемдә һәм саф һавада иҗади танып белү, интегральләштерелгән эшчәнлекләр, музыка белеме, мөстәкыйль эшчәнлек, шәхси эш.
Максат: экологик тәрбияне хәзерге заман социумына яраклашкан шәхес итеп, һәр балага иҗади һәм гармонияле үсеш бирерлек, балалар белән ата-аналарны эстетик матурлыкка тартырлык итеп оештыру.

**Бурычлар:**

**үстерешле:**

- балаларның экологиягә, культурага, танып белүнең төрле төрләренә омтылышны үстерү;
- иҗади активлыкны стимуллаштыру;

**белем бирү бурычы**:

- балаларда табигатьнең матурлыгын чынлыкта күрә белүне, дөньяви эстетик үсешне формалаштыру;

**тәрбияви бурыч**:

- балаларда табигатьне аңлый, саклый белергә, матурлыгын күрергә мохтаҗлык, рухи сыйфатлар тәрбияләү.

**Көтелгән нәтиҗә:**

1.Балаларда дөньяви эстетик үсешне, табигатьнең матурлыгын чынбарлыкта күрә, аңлый белүне формалаштырдык.

2.Балаларның һәм ата-аналарның рухи-әхлакый һәм иҗади сәләтләренең дәрәҗәсен күтәрдек.

Икенче кечкенәләр төркемендә Программаны тормышка ашыруның төп юнәлеше – балаларның танып белү, сөйләм, социаль-коммуникатив, сәнгати-нәфасәти, физик үсешенә шартлар тудыру. Төркемдә белем бирү процессы комплекслы һәм яңа буынның парциаль программалары нигезендә башкарыла. Программаның беренче планына белем бирүнең үстерешле функциясе куела. Программа балага гуманлы-шәхсипозициясендә төзелгән һәм аның һәрьяклы үсешенә, рухи һәм гомумкешелек кыйммәтләре, компетенциясе, сәләте формалашуга юнәлгән. Программада балаларга белем бирүдә каты регламентация юк. Программада уен эшчәнлеге аерым урын алып тора, баланың туганнан алып мәктәпкәчә чорына кадәр белем һәм тәрбия бирү процессы комплекслы бирелгән.

Программаның төп максаты – кучүчәнлек принципын тормышка ашыру һәм белем бирү системасы концепциясенә яраклаштырып мәктәпкәчә яшьтәге балаларга тәрбия һәм белем бирү. Әлеге программаның аермалылыгы шунда: мәктәп һәм мәктәпкәчә белем бирүнең өзлексез булуы проблеманы чынлыкта тормышка ашыра.

Программа Россия мәгариф академиясе тарафыннан тәкъдим ителгән.

### 1.1.Программаны формалаштыруның принциплары.

Россиянең төп бердәм мәктәпкәчә белем бирү программасының ФДББСка яраклашуы түбәндәгеләрдә күренә:

- балачакның үзенчәлеге;
- кешелекнең гомуми үсешендә мәктәпкәчә чорның уникаль булуы;
- өлкәннәр һәм балаларның гуманлы аралашуы;
- баланың шәхесен хөрмәт итү;
- балаларның спецификасын исәпкә алып, белем бирү процессын уен, танып белү, эзләнү, иҗади активлык формасында тормышка ашыру.

Программаны тормышка ашыруның төп принцибы- яшь үзенчәлегенә туры килү. Мәктәпкәчә чорда ул уен, тәҗрибәләр ясау, проектлау, коллекция туплау, әңгәмә кору, проблемалы ситуацияләрне чишү һ.б.Әлеге эш төрләре мәҗбүри эшчәнлекне таләп итми, ә бәлки Программа балалар һәм педагогларның бердәм эшчәнлеге, шулайук балаларның мөстәкыйль эшчәнлекләре аша тормышка ашырыла.

Интегральләштерү принцибы-предметлы белем бирү программасын төзүгә альтернатив. Һәр белем бирү өлкәсендәге бурычлар башка өлкәләрне тормышка ашырганда да үтәлә ала.Тәкъдим ителгән белем бирү өлкәләре шартлы, ул материалны системалы оештыру өчен бирелгән.

Проблемалы белем бирү принцибы – билгеле бер авырлыкларны җиңү өчен бурычларны үтәү, сорауларга җавап эзләү. Бала өчен проблеманың практик мәгънәсе булу бик мөһим. Проблеманы чишеп, бала дөньяның күптөрле, үзгәрүчән булуын белә.

Ситуатив принцибы – белем бирү процессында балаларның кызыксынучанлыгын исәпкә алуга юнәлгән.

**1.2.Максатчан юнәлешләр.**

Бала төрле эшчәнлектә мөстәкыйльлек күрсәтә: уен, аралашу, танып белү- эзләнү эшчәнлегендә, конструкцияләүдә һ.б.; шөгыль һәм эшчәнлектә иптәшләр сайлый. Бала үзенә, башкаларга, төрле эш төренә уңай карый ала, үзен-үзе хөрмәт итә. Яшьтәшләре, өлкәннәр белән актив аралаша, уеннарда катнаша, сөйләшә, башкаларның фикерен исәпкә ала, борчыла, шатлана. Үзенең эмоциональ халәтен тота белә, үз-үзенә ышана, бәхәсләрне чишәргә омтыла, якын кешеләренең эмоцияләренә җавап бирә, әйләнә-тирәдәгеләргә булышырга әзер тора; экият, хикәя, әсәр геройлары белән бергә борчыла, сәнгать әсәрләре, музыка, табигать дөньясына эмоциональ тәэсир итә, матурлыкны күрә белә, хайваннарга, үсемлекләргә сак карый. Баланың күзаллавы үсеш алган, уеннарның төрле төрен белә, шартлы һәм реаль ситуациянеаера. Бәйләнешле сөйләм телен җитәрлек дәрәҗәдә белә, фикерен әйтә. Баланың эре һәм вак моторикасы үсеш алган, хәрәкәтчән, чыдам, төп хәрәкәт төрләрен белә, үз хәрәкәтен контрольдә тота. Ихтыяр көче бар, төрле төр эшчәнлекнең кагыйдәләрен саклый, “нәрсә яхшы, нәрсә начар” күзаллавы буенча үзенең һәм башкаларның башкарган эшләрен бәяли. Бала кызыксынучанлык күрсәтә, сорау бирә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше белән кызыксына, мөстәкыйль рәвештә кешеләрнең кылган эшләренә, табигать күренешләренә бәя бирергә тырыша, тәҗрибә ясарга һәм күзәтергә омтыла. Бала тарих һәм культура белән кызыксына, башка милләт культурасына игтибар итә башлый. Табигать, социаль дөнья, үзе турында башлангыч белемгә ия. Балалар әдәбияты, тере табигать, табигать белеме, математика, тарих һ.б. буенча иң гади күзаллавы бар. Эшчәнлекнең төрле өлкәләренә һәм белеменә таянып, үзе төрле ситуациядән чыга ала. Бала кагыйдә, үрнәк, гади алгоритм (3-4 адым) буенча эшли белә, өлкәннәр ярдәмендә авырыксынган сорауларны чишә, сәбәпләрен ачыклый һәм танып белү бурычын формалаштыра, ирешелгән нәтиҗәне һәм шартны теркәп куя.

# 2. Эчтәлек бүлеге.

## 2.1. Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге

## Социаль –коммуникатив үсеш өлкәсе

3-4 яшьлек балаларның фикерләүләре үзенчәлекле булганга, баланың үз-үзен тотышында үзеннән-үзе көйләнү процессы өстенлек ала башлый, ирекле психик процессларның үсеше

балаларның төрле өлкәдә тотрыклы оешуына китерә, хәрәкәтләрнең кагыйдәләргә буйсынуы төрле конфликтлы ситуацияләрнең килеп чыгуын булдырмый кала. Балаларның социаль культураның төрле төрләре турындагы белеме дифференцияле характер ала һәм алар продуктив , иҗади эшчәнлекнең төрле төрләрендә кулланыла.Программаны тормышка ашыру балалар белән эшчәнлекнең төрле ысулларын һәм алымнарын күздә тота (әкиятләрне сәхнәләштерү, әңгәмә, экскурсияләр, матур әдәбият уку, сюжетлы-рольле, дидактик уеннар, сөйләм, музыка тыңлау һ.б.), үзенчәлекле балалар эшчәнлегенең иң уңайлы яраклашуын фаразлый (коммуникатив, уен, танып белү, сөйләм, рәсем сәнгате, конструктив, музыка һ.б). <u>Мин-Кеше</u>: мин-малай, мин-кыз. Аларның охшашлыгы күп: уйнарга, җырларга, биергә, хайваннарны карарга, туганнарын, әти-әниләрен яраталар; төрле хисләр кичерәләр: моңсуланалар, шатланалар, елыйлар, сагыналар,дулкынланалар, ләкин төрлечә кичерәләр. Кешенең хисләрен йөзенә, тавышына, хәрәкәтләренә карап әйтеп була.Әгәр кешенең йөзе моңсу булса, тавышы акрын, җилкәләре төшкән, башы иелгән була, аңа начар, аңа булышырга: нәрсә булганын сорарга, кочакларга, сыйпарга, җылы сүзләр әйтергә, шәфкатьлелек күрсәтергә кирәк.Шәфкатьле кеше һәрвакыт башка кешенең авыртуын күрә, аңа ярдәмгә ашыга. <u>Малайлар һәм кызлар</u> бер-берсе, хайваннар, кечкенәләр, ата-аналар турында кайгырталар. Кызлар кайгыртучанлык, ягымлылык, яхшы күңеллелек күрсәткән чын хатын-кыз эшләрен бәяли. Малайлар - кыюлык, намуслылык, көч, вөҗданлылыкны. Вөҗданлы булу-ул үзеңнең нәселеңне данлау, аны бөртекләп яхшы эшләр белән тулыландыру. Малайларның һәм кызларның кызыксынулары төрлечә: малайлар шау-шулы уеннар, конструктор, чик сакчылары, янгын сүндерүчеләр булып уйныйлар, машина, танклар ясыйлар. Кызлар курчаклар, өйле уеннар уйныйлар, киенәләр; чәчәкләр, өйләр, кешеләр  ясыйлар. Киресенчә дә булырга мөмкин. Ләкин бер-берсенең кызыксынучанлыгын хөрмәт итеп, комачауламый уйнарга кирәк.

<u>Ир-ат һәм хатын-кызлар</u> күбесенчә бер-берсенә охшаган: аралашырга, кунакка йөрергә, бүләк алырга яраталар. Хөрмәткә лаек ир-ат йомшак, зәгыйф кешене яклый, саклый, өлкәннәргә ярдәм итә, үз өстенә җаваплылыкны ала, намуслы, батыр, кыю. Хөрмәткә лаеклы хатын-кыз һәрвакыт ачык йөзле, кайгыртучан, аның янында тыныч, җылы, рәхәт була, ул тәмле ашата, назлый, тынычландыра, тәртип булдыра ала. Түземлелек, тырышлык, җентекләп эшләүне таләп итүне хатын-кыз башкара.
<u>Минем гаиләм.</u> Гаилә якын һәм ерак туганнардан тора. Якын туганнар – әти, әни, әби, бабай, апа, абый, эне, сеңел. Ерак туганнар-әти-әнинең абый-апалары. Һәр гаиләдә “хатын-кызлар”, “ир-атлар” бәйрәме үткәрелә. Гаиләдә ир-атлар һәм хатын-кызларны төрлечә атыйлар. Малай гаиләдә –ул, абый, эне, онык; кыз – кыз бала, апа, сеңел, онык; ир-ат – әти, ул, ир; хатын-кыз –әни, кыз, хатын. Гаиләдә иң хөрмәтле кешеләр – әби, бабай, алар турында кайгырталар, аларны саклыйлар.
<u>Балалар бакчасы.</u> Балалар бакчасы һәркемгә кадерле. Анда эшләүчеләр балаларга әйбәт булсын дип кайгырталар: пешекче, тәрбияче ярдәмчесе,ишек алды җыештыручы, тәрбияче, өлкән тәрбияче, кер юучы, шофер, мөдир. Бакчада эшләүче өлкәннәр балаларга яхшы булсын өчен күп эшлиләр: үсемлекләр турында кайгырталар, веранда буйыйлар, кар төзелешләр ясыйлар. Балалар аларга хөрмәт белән карыйлар: исеме, әтисенең исеме белән дәшәләр, елмаялар, бәйрәмнәр белән котлыйлар, бүләкләр бирәләр.
<u>Кешенең килеп чыгуы һәм үсеше</u>. Һәр кешенең үз тарихы бар. Кешенең тарихы ул туганнан соң башлана. Ул туган вакытны туган көн дип атыйлар. Бала бераз үсә төшкәч, бакчага бара, күп нәрсәгә өйрәнә, дуслар таба. Бакчадан соң мәктәпкә бара, бала дөнья, тормыш турында күп нәрсәгә өйрәнә, үзе эшли. Мәктәпне тәмамлагач, алга таба укырга керә яки эшли башлый. Зур кеше булгач,гаилә кора, балалар үстерә. Картайгач, пенсиягә китә, өйдә ял итә, сәяхәткә китә. Өлкән кешеләр күп беләләр, тормыш тәҗрибәсе туплыйлар. Аларга булышырга кирәк.

Гаилә тарихы. Һәр кешенең исеме бар, исем ул тугач бирелә. Исемнәр төрле була, алар нәрсә дә булса аңлата. Гаилә әгъзалары, аларның бер- берсенә карата кайгыртучан мөнәсәбәттә булулары турындагы белемнәрен арттыру. Әти- әнинең иң кадерле кешеләр булуын, аларны яратырга, эшләгән эшләренә хөрмәт белән карарга, әти- әниләрне хөрмәтләргә кирәклеген төшендерү. Әби- бабайларга карата игътибарлы, ярдәмчел булырга өйрәтү.Аларга яратып, ягымлы итеп эндәшергә күнектерү.

Туган шәһәр. Һәр шәһәрнең тарихы була, яңа, иске, борынгы шәһәрләр бар.Борынгы шәһәрләр кешегә яшәү өчен җайлы урында барлыкка килгән: яңа шәһәрләр файдалы казылмалар(нефть, күмер) булган җирдә, ял итә торган урыннарда (диңгез, күл) Һәр шәһәрнең туган көнен, тарихын билгели торган күп кенә башка даталары бар. Һәр шәһәрдә дә музей, һәйкәлләр, урамнар, аларның үз исемнәре, тарихы бар: алар күренекле кешеләр исемнәре белән атала.

Туган ил. Туган авылның(шәһәр, бистә) исемен әйтергә өйрәтү. Ял көннәрендә кайларда булулуры турында сөйләргә теләк уяту. Урамда үз- үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен өйрәтү.Өйдәге, балалар бакчасындагы вакыйгаларның мәгънәсен төшендереп, нәниләрдә шатлык хисләре тудыру.

Татар милли культурасы. Йорт төзелешләре яшәр өчен төзелгән. Татарлар йорт хайваннары асраганнар, игенчелек белән шөгыльләнгәннәр. Бөтен төр хезмәтләр дә бер- берсенә бәйле булган: тегермәнче-игенчегә, балта остасы-агач кисүчегә, терлекче- тимерчегә.Шуңа кешеләр дус, тату яшәгәннәр, шул турыда әкиятләр, җырлар, мәкальләр уйлап чыгарганнар. Табигать кешеләрне туендырган, җылы биргән, киендергән, дәвалаган. Кешеләр әйләнә-тирәгә булган мөнәсәбәтләрен әкиятләрдә, җырларда чагылдырганнар. Аларда намуслы яшәү, бер-береңә авыр вакытта булышу, өлкәннәрне, ата-аналарны хөрмәтләү, туган илне ярату сурәтләнгән.

Сюжетлы-рольле уеннар. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның тормышында сюжетлы-рольле уеннар аерым урын алып тора. Педагог балаларны уен сюжетын үстерергә өйрәтә, башкаручылар арасындагы мөнәсәбәтне ныгыта, таныш уен сюжетларын берләштерә, шуларның берсен төп сюжет итеп алырга һәм балаларга рольләр тәкъдим итә, кара-каршы сөйләмне формалаштыруны, рольләрне башкаручыларның эш-хәрәкәтен планлаштыруны дәвам итә. Педагог уен барышында туган традицион һәм заманча мөстәкыйль уен эшчәнлеген хуплый: “Шифаханә”, “Гаилә”, “Кибет”, “Чәчтараш” “Шофер”, “Төзүче” һ.б.

Эксперимент уеннар – бу яшьтәге балалар өчен әһәмиятле урын тота. Алар балага югары дәрәҗәдәге мөстәкыйльлек кенә биреп калмыйлар, ә үз-үзләрен ачарга мөмкинлек бирәләр.

Театр уеннары. Икенче кечкенәләр төркемендә сәхнәләштерелгән уеннар балаларның мөстәкыйльлеген үстерә, курчак спектакльләре, сәхнәләштерелгән уеннарның барышын күзәтүне формалаштыра.Тәрбияче балаларны персонажларның төрле хәрәкәтләрен күрсәтергә генә өйрәтеп калмый, ә геройларның эмоциональ халәтен күрсәтү сәләтен дә үстерә (мимка, поза). Педагог курчакларны йөртү (бибабо, өстәл курчаклары һ.б.) белән таныштыра, хәрәкәтләрне җыр белән башкара.Балалар рольләрне башкарганда костюм элементлары куллану аларга үзләрен тегеяки бу образда итеп хис итү өчен әһәмиятле. Образга кереп уйнаганда балада иҗади мөстәкыйльлек, нәфасәти зәвык тәрбияләнә.

Режиссер уеннары. Икенче кечкенәләр төркемендә режиссер уеннары әкренләп катлаулана һәм төрләнә бара: катнашучылар күбәя, аларның үзара бәйләнеше дә катлаулана, төп һәм уртача геройлар билгеләнә.

**Коммуникатив сәләт үсеше**. Ситуацияне исәпкә алып аралашу, әңгәмәдәшенә ориентлашу коммуникатив сәләт үсешенең әһәмиятле шарты булып тора. Бала өлкәннәр инициативасы белән туган әңгәмә темасын дәвам итә, сорауларга җавап бирә, кире кага ала. Балаларда сөйләм культурасын үстерү мәктәпкәчә белем бирү

оешмаларында гына түгел, ситуациягә карап сөйләм этикетың төрле формаларын һәм кагыйдәләрен күзаллауны формалаштыру нигезендә гаиләдә дә әһәмиятле: ата-аналар балалар белән бергәләп хикәяләр уйлап чыгара, аларның рәсемнәрен ясый, әдәби әсәрләрне укыганнан соң әңгәмә алып баралар. Балаларны вербаль булмаган аралашу чараларын(мимика, жест),төрле интонацияләр кулланырга, сөйләмнең темпын һәм тавыш көчен сакларга  өйрәтү әһәмиятле.

**Куркынычсызлык куьтурасын формалаштыру**. Безнең төркемдә турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге белем бирү ситуациясе формасында тормышка ашырыла, аның барышында балалар әйләнә-тирәнең төрле аспектлары белән танышалар, билгеле бер вакыйгага анализ ясарга, куркынычсызлык кагыйдәләренең асылына төшенергә, аларны мөстәкыйль формалаштырырга өйрәнәләр. Төп басым балаларны төрле төр эшчәнлекнең культуралы  һәм куркынычсыз башкарылган  моделе белән таныштыруга ясала. Белем бирү структурасы психик процессларныңүсешенә ярдәм итә.  Белем бирү ситуациясе зурлар төркемендә турыдан-туры белем бирү эшчәнлеген оештыруның төрле формадагы компоненты булырга мөмкин: эзләнү, практик-ориентлашу, иҗади проектлар, сюжетлы-рольле уеннарга алдан әзерлек, практикумнар, иҗади мастерскойлар, шөгыльләр. Турыдан-туры белем бирү эшчәнлеге вакытында алган күзаллаулар һәм тәҗрибәләр режим моментларында үткәрелгән белем бирү эшчәнлегендә тормышка ашырыла. Иртән килгән балалар белән  куркынычсызлык кагыйдәләре турында белемне актуальләштерергә ярдәм итүче әңгәмәләр үткәрелә, хезмәт вазифаларын, гигиена процедураларын башкарганда, уен эшчәнлеге барышында куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүгә игътибар бирелә. Саф һавада максатчан йөргәндә,хәрәкәтле уеннар уйнаганда, хезмәт эшчәнлеге вакытындакуркынычсызлык кагыйдәләре саклана. Матур әдәбият белән танышканда, музыка әсәрләре тыңлаганда, сынлы сәнгатьтә, яраткан экиятләрне сәхнәләштергәндә, мультфильмнар, видеофильмнар караганда, иҗади эшләрдә куркынычсызлык культурасы образлы күзаллаулар формасында тирәнәйтелә. “Физик үсеш” үстерешле өлкәсе балаларга үз сәламәтлегенә аңлы караш тәрбияли. Программа гаиләдә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүгә игътибар бирә. Мәсәлән, “Таныш булмаган кешеләр белән аралашканда куркынычсызлык” бүлегендә педагоглар балаларны матур әдәбият әсәрләре белән таныштырып, ситуацияне анализлый, персонажларның үз-үзен тотышын бәяли, алынган мәгълүматларны сюжетлы-рольле, режиссер уеннарына кертә. Ата-ана үрнәк бып тора. Гаилә, ата-ананың төп бурычы-куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүне игътибар үзәгендә тоту.

Табигать һәм куркынычсызлык. Танып белү өлкәсендә алган белемнәр нигезендә балаларда төрле үсемлекләр, гөмбәләр белән килеп чыккан ситуацияләр нәтиҗәсендә балаларның табигатьтә үз-үзләреннең тотышлары турында күзаллау фомалаша. Матур әдәбият белән танышканда , күзәтүләр нәтиҗәсендә, продуктив эшчәнлектә балаларда үсемлекләргә, аеруча куркынычлы хайваннарга (елан, талпан), гөмбәләргә сак караш тәрбияләнә. Табигатьтә була торган хәвефле ситуацияләрдән саклану, аларны булдырмау чаралары өйрәнелә.

Урамда куркынычсызлык. “Гаилә”, “Светофор”, “Машина йөртүчеләр” сюжетлы-рольле уеннарын, режиссер, дидактик уеннар уйнаганда, матур әдәбият әсәрләре укыганда, экскурсияләр, күзәтүләр үткәргәндә, мультфильмнар, телетапшырулар караганда балаларда шәһәр урамнары төзелеше, юл хәрәкәте, машиналар турында күзаллау формалаша, алар юл хәрәкәте кагыйдәләре белән танышалар.

Өйдә куркынычсызлык. Педагог балаларны өйдә куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныштыра, үзеңнең өй адресыңны белүнең әһәмиятен ачыклый, проблемалы ситуацияләрдә үзеңне ничек тотарга кирәклегенә өйрәтә.

**Хезмәт. Өлкәннәр хезмәте белән таныштыру**. Педагог балаларны төрле һөнәр ияләренең хезмәте белән таныштыра(тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе, музыка җитәкчесе, табиб, сатучы, пешекче, шофер, төзүче) аларның хезмәт төрләре һәм хезмәт нәтиҗәләре турындагы күзаллауларын киңәйтү. Балаларда өлкәннәрнең хезмәт эшчәнлеген көчләреннән килгәнчә ярдәм итәсе килү теләге тудыру. Һәрбер һөнәр иясенең хезмәт нәтиҗәсенә хөрмәт белән карарга өйрәтә, һәр хезмәт эшчәнлеге арасындагы бәйләнешне күрергә ярдәм итә.
**Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү**. Педагог балаларга билгеле бер тәртиптә мөстәкыйль киенергә, чишенергә (кием кию,аны салу, төймәләрне чишү һәм төймәләү, төреп яки элеп кую, ботинкаларның бауларын чишү һәм бәйләү)пөхтәлеккә киемнәрдәге җитешсезлекне күрергә һәм өлкәннәр ярдәме белән аны бетерергә, культура-гигиена күнекмәләре бирә, мөстәкыйльлекне мактый һәм нәтиҗәне бәяли. Балаларның культура эшчәнлегенә : чиста ашау, тавышсыз эчү, чәнечке  (яңа елдан соң) куллану, салфеткадан файдалану һ.б. игътибар бирә.
<u>Хуҗалык-көнкүреш хезмәте –</u> балаларның төркем, аш бүлмәсендәге, мәйданчыктагы хезмәтләрен хуплый, эшчәнлекләрдән соң эш урынын җыештырырга өйрәтә.
<u>Табигатьтәге хезмәт.</u> Педагог балаларны табигать объектларын карарга тарта. Шул ук вакытта тере объектларның экологик, биологик, географик үзенчәлеген исәпкә алып аларга сак карарга, эш коралларын чиста тотарга, җәй көне бакча эшләренә, ташландык әйберләрдән уенчыклар ясарга өйрәтә.

## Танып белү үсеш өлкәсе

**Әйләнә-тирә белән танышу**. Балалар табигать күренешләре белән кызыксыну тудыру, һава торышын билгеләргә һәм әйтеп бирергә, ел фасылларының характерлы үзенчәлекләре белән таныштыра башлау.  Балалар бакчасындагы агачлар, куаклар, гөмбәләр, бөҗәкләр,кошлар белән күзәтүләр үткәрәләр. Үз тирәлегенең сулары, анда яшәүче җан ияләре белән танышалар.Тәрбияче балаларга табигатьтә һәрбер җан иясенең кирәклеге турында сөйли. Ташлар, ком, балчык,  белән таныштыруны дәвам итә.
**Танып белү-эзләнү эшчәнлеге**.Тәрбияче предметларның үзлеген аерып күрсәтергә өйрәтә (көпшәк, каты, бөгелүчән, ныклы, уалучан һ.б.) . Предметның яңа үзлекләре белән таныштыруны оештыра, төрле материалларны (кәгазь, картон, тукыма) танырга, сүзләр белән атарга (пластмасс, йон, мех һ.б.) өйрәтә. Кәгазьнең ничек ясалуын, аны файдалы куллану; төрле материалны ясаганда әйләнә-тирәнең ничек пычрануын, чүп-чарның ничек килеп чыгуын һәм кая китүен, аларның кире эшкәртелүен сөйли. Сыеклыкның агуын, таралучан әйберләрне салырга кирәклеген аңлата. Балалар тере һәм тере булмаган объектларны чагыштырырга, аларның бәйләнешләрен аңларга өйрәнәләр. Тәрбияче балаларны бакчаның планы, экологик сукмак, шартлы билгеләр белән таныштыра, күзәтүләр, тәҗрибәләр өчен шартлар тудыра: мини-лабораториядә табигый байлыклар, ясалма һәм ташландык материаллардан тәҗрибәләр өчен эш кораллары ясыйлар. Балалар үзлектән гипотеза төзиләр, нәтиҗәне чагыштыралар.
**Иң гади математик күзаллауны формалаштыру**. Икенче кечкенәләр  төркемендә эшчәнлекнең әкренләп гамәлнең предмет белән модельдән  математик график модельгә күчүе яңа караш булып тора. Шул максаттан чыгып, эш дәфтәрләре кулланыла башлый, балаларга мөстәкыйль проблемалы ситуация бирелә.
<u>Предметларны чагыштыру.</u>Төркемдәге  предметларның уртак  билгеләрен  күрә белә

күнекмәләрен үстерү. Балаларны бер төрле предметлардан төркемнәр төзергә һәм шулардан аерым предметларны аерып алырга ,күп,бер, берәмләп төшенчәләрен белергә, әйләнә- тирәдән бер һәм күп предметларны табарга, “Ничә?” соравын аңларга, җавап биргәндәкүп, бер, бер дә юк сүзләреннән файдаланырга өйрәтү.
Бер предметны икенчесенең өстенә, астына,янына куюю юлы белән тигез һәм тигез булмаган төркемнәрне чагыштырырга, бер берәмлекне кушып йә алып тигез булмаган төркемнәрне тигезләргә өйрәтү.
Сан ягыннан тигез булмаган төркемнәрне чагыштырганда, кимрәк санлы төркемгә бер предмет өстәп яисә артыграк санлы төркемнән бер предметны алып, тигезлек урнаштырыргаөйрәтү.
Зурлык. Зурлыкларына карап (озынрак- кыскарак, киңрәк- таррак, зуррак- кечерәк) ике предметны чагыштырырга, предметларны озынлыгы, киңлеге һәм биеклеге буенча чагыштырганда, аларны берсе өстенә икенчесен кую һәм янәшә кую ысулыннан файдаланырга, эш нәтиҗәләрен сүзләр белән әйтә белергә күнекткрү, өйрәтү.(озын- кыска- озынлыклары тигез: киң- тар- бердәй киңлектә).
Форма.Түгәрәк, квадрат, өчпочмакны танып белергә, күреп, капшап карап фигураларның формасын билгеләргә өйрәтү.
Тирә- юньдә һәм вакытта ориентлашу. Балаларны уң һәм сул кулларын күрсәтә, үзенә карата пространство юнәлешләрен билгеләргә, тәүлекнең капма- каршы өлешләрендә ориентлашырга өйрәтү: иртә- кич, көн- төн.
**Конструкцияләү.** Саф һавада булганда, экскурсияләр вакытында педагог балаларны дизайн иҗатының төрле төрләре (архитектура, интерьер, автомобиль, җиһазлар, уенчыклар һ.) белән таныштыра.Балалар төзегән корылмлар, конструкцияләр һәм әйләнә-тирәләрендә күрә торган корылмалар (өйләр, ишегалды һ.б.) арасында бәйләнеш урнаштыра белергә, конструкцияләрнең төп өлешен һәм характерлы детальләрен күрсәтә белергә өйрәтә. Балаларда күмәк эшләү, эшләрен уртак ниятләре белән яраштырып берләштерү күнекмәләрен бирә, мөстәкыйльлекне, иҗадилыкны хуплый. Балаларның үсеше түбәндәге конструктив эшчәнлек чаралары ярдәмендә бара: 1. Тәҗрибәләрне туплау һәм гомумиләштерү өчен иң уңайлы шартлар тудыру. 2.Үзләштерелгән алымнарның төрле ситуацияләргә инициативалы күчеше. 3. Мөстәкыйль эшчәнлектә ирекле алымнар куллану (конструктив, уен, сәнгать). 4.Уен һәм күнегүләрдә шартлы уенчыклар куллану. 5. Практик эшчәнлекнең эчке планга (фикерләү, күзаллау) күчүе, фикерләүнең үзгәрүе, нәтиҗәне фаразлау һәм иң гади мәсьәләләрне чишү– форма һәм конструкция белән күңелдән тәҗрибә ясау ул.

## **Сөйләм үстерү үсеш өлкәсе**.

*Авазларны дөрес әйтергә өйрәтү.*Сөйләм органнарын хәрәкәтләндерергә һәм һәр авазны өйрәткәндә тел хәрәкәтен билгеләргә, тавыш көче белән идарә итә белергә өйрәтү. Балаларның авазларны ничек әйтүләрен ачыклау. Балаларны сүзләрдәге сузык авазларны (а, ә, у, ү, о, ө, э, и) һәм алдагы эзлеклелектә кайбер тартык авазларны: п-б-т-д-к-г,ф-в, т-с-з-ц ачык итеп сөйләшергә өйрәтү.Авазларны дөрес әйтергә ярдәм итә торган сүзле, дидактик уеннарны һәм аерым авазлар ешрак кабатланган шигырьләрне, тизәйткечләрне куллану. Сәнгатьле сөйләм өстендә эшләү.
*Сүз байлыгын үстерү.* Тирә-юнь турындагы белемнәрен киңәйтү исәбенә, балаларның сүз байлыгын арттыру һәм активлаштыру. Көнкүреш предметларын белдерүче,әйберләрнең өлеш- кисәкләрен, сыйфатларын, өслекнең үзенчәлекләрен, кайбер материалларны һәм аларга хас сыйфатларны, кайда урнашканын әйтә белергә, кулланышлары белән охшаш булган әйберләр арасындагы аерманы күрә белергә, уенчык, кием- салым, савыт- саба, җиләк- җимеш, яшелчә, кошлар кебек

гомумиләштерүче сүзләрнең  мәгънәләрен аңлый белергә өйрәтү. Тәүлекнең өлешләрен тышкы күренешләренә карап, йорт хайваннары һәм аларның балаларын, җиләк- җимеш һәм яшелчәләрне аеру.
*Сөйләмнең грамматик төзелеше.* Балаларны исемнәрене сыйфатлар белән яраштырырга, килеш, тартым, сан белән төрләндерергә өйрәтү. Исемнәрне (белән, саен, өчен, кебек) белән куллану.Хайваннарның, кошларның, әйберләрнең атамаларын берлек санда һәм күплек кушымчалары ялгап, дөрес итеп әйтергә өйрәтүне дәвам итү. Исемнәрнең килеш белән төрләнешен, күплек сандагы исемнәрнең  килеш белән төрләнешен ныгыту.Яңа сүзләр ясый белү осталыгын грамматиканы яхшы белергә дип кабул итү, сүзләренең дөрес формаларын өйрәтү. Гади җөмләләрдән сыйфат, тәмамлык, хәлләр кулланып, катлаулы җөмләләр,тиңдәш кисәкле җөмләләр төзергә ярдәм итү.
*Бәйләнешле сөйләм.* Рәсем,иллюстрация, уенчыклар, тере объектларны, төзелеш эшләрен күзәткәндә, спектакльләр, мультфильмнар караганнан соң  тәрбияче биргән сорауларга җавап бирергә, кара- каршы сөйләшергә (диалог) өйрәтү. Үз фикерләрен бәйләнешле, эзлекле итеп әйтә белү күнекмәләре формалаштыру. Гаиләдә, төркем бүлмәсендә өлкәннәргә, яшьтәшләренә, “рәхмәт”, “исәнмесез”, “ сау булыгыз”, “тыныч йокы” кебек сүзләр әйтү зарурлыгын төшендерү, үтенечен ачык итеп, “зинһар” сүзен кушып белдерергә күнектерү.
Таныш әкиятләрне рольләргә бүлеп сөйләргә, сәхнәләштерүдә катнашу теләге тудыру. Бер –берсе белән  яхшы мөнәсәбәттә булырга ярдәм итү. Татар халык иҗаты белән тулырак таныштыра башлау.
***Русский язык****.Задачи обучения русскому языку детей 3-4 лет* ***(УМК)*** формирование, развитие умений и навыков аудирования, говорения в игровых ситуациях по темам “Игры и игрушки” “Дом, в котором я живу”, “Посуда и продукты питания”, “Сад и огород”, “Транспорт”, “Одежда и обувь”, “Домашние и дикие животные”.
Обогащение активного словарного запаса существительными, прилагательными, глаголами, наречиями, местоимениями, числительными; формирование умений согласовать части речи. Выработка умений и навыков понимать смысл предложений с вопросительнымизнаками. Различать значения предлогов в, на. Выработка умений и навыков вести диалог, составлять рассказы, описания. Разучивание стихотворений, песен, считалок на русском языке.

## Нәфасәти үсеш өлкәсе.

**“Матур әдәбият һәм фольклор” юнәлеше**. Икенче кечкенәләр  төркемендә матур әдәбиятне кабул итү укылган әкиятләр, кечкенә хикәяләр, шигырьләр тыңларга, аларның эчтәлеген аңлый белергә өйрәтү. Татар халык авыз иҗатының гүзәл үрнәкләре- юаткычлар, эндәшләр, такмаклар, бармак уеннары белән таныштыру эшен дәвам итү. Шигырьләрне  яттан сәнгатьле итеп сөйләү күнекмәләре бирелә.Текстны рольләргә бүлеп уку, әсәрләрне сәхнәләштерү күнекмәләре булдыруга булышлык итә. Китаплар белән таныштыру эше дәвам итә.
**“Продуктив сәнгать эшчәнлеге”**. Блаларның *сынлы сәнгать* белән кызыксынуларын үстерү өстендә эшләү. Кабул итү органнары эшчәнлеген (күрү, ишетү, тою) үстереп, балаларның сенсорик тәҗрибәсен баету. Нәфасәти кабул итү сәләтен үстерү.
*Халык декоратив-гамәли сәнгате* Балаларны декоратив рәсем ясауэшчәнлегенә тару. Татар милли әйберләре бизәргә өйрәтү.Яфрак бизәгән рәсемгә төшерү. Яңа төсләр белән таныштыру.(алсу, сыек зәңгәр). Төсләрне сайлый белү күнекмәләре бирү Дымково бизәкләре белән уенчык силуэтын һәм төрле предметларны бизәргә өйрәтү.Сызык, штрих, буялыш(мазки), тимгел- тимгел тапларны ритмик рәвештә

төшерергә, гади предметларны сурәтләргә, төрле юнәлештә туры сызыклар сызарга, аларны кисештерергәөйрәтү.

Балаларны төрле материаллардан *әвәләүнең* үзенчәлекләре белән таныштыруны дәвам итү. Натурадан карап, күзаллап таныш предметларны әвәләп ясау күнекмәләрен үстерү, характерлы үзенчәлекләрен, кисәкләрне пропорцияләре һәм детальләр зурлыгындагы аерымлыкларны чагылдыра белүләренә ирешү. Әвәләгәндә образның мәгънәлелеген чагылдырырга, кеше һәм хайван сыннарын хәрәкәттә әвәләргә, зур булмаган предмет төркемнәрен гади сюжетка берләштерергә өйрәтү.

*Декоратив әвәләү* үзенчәлекләре белән таныштыруны дәвам итү. Катлаулы булмаган әйберләр: күмәч, коймак, бавырсак, чәчәк һ.б. төрле савытлар әвәләргә, аларны таякчык белән бизәргә,турыга әвәләгәндә барлыкка килгән таякчыкны бөҗра ясап тоташтыру, шарны басып яссыландыру, 2-3 кисәктән торган предметларны, бер-берсенә кысып ябыштыру юлы белән әвәләргә өйрәтү. Пөхтә эш итү күнекмәләрен ныгыту, шатлык хисе уяту.

*Кисеп ябыштыру*. Балаларны кисеп ябыштыру эшчәнлегенә тарту, аларда бу эшчәнлеккә кызыксыну уяту. Тәрбияче тарафыннан әзерләнгән бала уйлаган яки тәрбияче тәкъдим иткән предметны төзергә, килеп чыккан сурәтне кәгазьгә ябыштырырга өйрәтү. Пумала белән эш итәргә , чиста, пөхтә эш күнекмәләре өйрәтү.Үзләре тудырган сурәттән шатлык хисләре уяту.

**Музыка тәрбиясе.**Балаларны композиторлар турында кыскача белешмәләр, классик, халыкчан һәм заманча музыкаль әсәрләр белән таныштырып, музыкага мәхәббәт тәрбияләү, кызыксыну хисләрен, нәфасәти тойгыларын үстерүне дәвам итү.Музыкаль сәләтләрен (музыканы ишетү, хәтер, ритм тойгысы, тембрларны аеру), музыкага карата мөнәсәбәтләрен үстерүне дәвам итү.

| | **Тема. АЛСУНЫ УРАМГА КИЕНДЕРӘБЕЗ.** | **Бурычлар:**1) кышкы киемнең билгеләнешен, төсен, детальләрен, материалын аерып алып, аны карарга өйрәтү, исемне сыйфат белән туры китереп, сорауларга җавап бирүне дәвам итү;2) тукыма, мех, йомшак, җылы, шома, ак, яшел (зәңгәр) сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыру, конкрет-образлы фикерләүне, игътибарны, күрү хәтерен үстерү;3) киемнәргә карата сакчыл караш тәрбияләү. **Җиһазлар:** кәрҗин, анда тукыма, мех кисәкләре. Кышкы киемнән Алсу курчак: куртка, башлык, итекләр, бияләйләр. Төзү матералы | Туган телдә сөйләшәбез |
| | **Тема. КАР ЯВА** | **Бурычлар:**1) балаларның кыш турында күзаллауларын киңәйтү, кар, аның билгеләре белән таныштыруны дәвам итү, сөйләмдә сыйфатларны дөрес куллана белү осталыгы камилләштерү;2) балаларның игътибарын, диалоглы сөйләмен, рәсем ясауга кызыксынуларын, пространствода ориентлашуларын, сөйләм сулышын үстерү; 3) | Туган телдә сөйләшәбез |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләү.**Җиһазлар:** һәр балага җитәрлек мамык кисәкләре, һәр балага җитәрлек зәңгәр төстәге кәгазь битләре, ак гуашь, куян уенчыгы, кыш темасына аудиоязма. | |
| январь | **Тема ТЕРЕМКӘЙ” РУС ХАЛЫК ӘКИЯТЕН СӨЙЛӘҮ. “** | **Бурычлар:**1) балаларны әкиятне игътибар белән тыңларга, сюжетның эзлеклелеген күзәтә белергә өйрәтү;2) Тычкан-Чыелдык, бака-Бакылдык, куян-Куркаккай, төлке-Хәйләбай, бүре-Соры колак, аю- Камыт аяк сүзтезмәләре хисабына балаларның сүзлеген активлаштырырга, ихүтибарны, ишетү, күрү хәтерен үстерү;3) халык иҗатына кызыксыну тәрбияләү.**Җиһазлар:** фланелеграф (коврограф), “Теремкәй” әкиятенең персонажлары, битлекләр, кыршаулар, төзү материалы. | Туган телдә сөйләшәбез |
| | **Тема: “КЕМ НӘРСӘ ЯРАТА?” ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЕН СӨЙЛӘҮ** | **Бурычлар:** 1) әкиятнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, сорауларны аңлау һәм аларга җавап бирү осталыгын камилләштерү, балаларның йорт кошлары һәм хайваннары турындагы кузаллауларына төгәллек кертү, аваз иялтемнәрен ачык һәм дөрес әйтүдә күнектерү;<br><br>2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, образлы фикерләүләрен, ишетү сәләтен үстерү;<br><br>3) кошларга, хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү<br><br>**Җиһазлар:** песи, эт, этәч, кәҗә уенчыклары, “Безнең дусларыбыз” җырының аудиоязмасы *(М. Хөсәен сүзләре, А. Ключарев сузләре* | |
| | **Тема: ТӘРҖЕМАНОВНЫҢ “ ҮЗЕН БИК ЧИСТА ЙӨРТӘ” ШИГЫРЕН УКУ.** | **Бурычлар:**1) балаларны яңа шигырь белән таныштыру, аның эчтәлеген аңлап, кабул итүләрен камилләштерү, сорауларга төгәл итеп җавап бирүдә күнектерү;<br><br>2) кабул итүләрен, игътибарын, | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | хәрәкәтләрен, фикерләүләрен үстерү;<br>3) балаларда пөхтә һәм чиста йорү теләге тәрбияләү. | |
| март | **Тема. КОЯШ ГОМЕРЕ ТЕЛИМ МИН, ӘНИЕМ СИҢА!** | **Бурычлар:**1) балаларның әниләр бәйрәме, әниләре турындагы белемнәрен киңәйтү, [ә] авазын ачык итеп әйтү осталыгын камилләштерү, әңгәмәдә катнашуга җәлеп итү;2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, диалоглы сөйләм формасын үстерү;3) балаларда әниләргә мәхәббәт һәм аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү.**Җиһазлар:** балаларның әниләренең фотолары, "Кояш гомере телим мин" (сүз., көе) "Әниләр бәйрәме" (Гариф Гумер сүз., М.Бикбова көе) җырының аудиоязмасы яңгырый. җырының аудиоязмасы. | Туган телдә сөйләшәбез |
| май | **Тема. БОЗАУ, КОЛЫН, БӘРӘН ТУРЫНДА СӨЙЛИБЕЗ** | **Бурычлар:**1) язгы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре турында күзаллауларын киңәйтү, тәрбияче белән бергә уенчык турында кечкенә хикәя (2-3 җөмлә) төзергә, кире мәгънәдәге сүзләрне (зур - кечкенә, калын – нечкә) аера белергә өйрәтүне дәвам итү, балаларның аваз ияртемнәрен әйтә белүләрен ныгыту; 2) балаларның кабул итүләрен һәм монологлы сөйләмен, кул хәрәкәтләрен үстерү;3) балаларда хайваннар тормышына кызыксыну тәрбияләү.**Җиһазлар:** сарай-ширма, ат – колын, сыер – бозау, сарык – бәрән уенчыклары, чирәмлек рәсеме, колын, бозау, бәрән уенчыклары, тәлинкәгә салынган су балалар санынча алына. | Туган телдә сөйләшәбез |
| | **Тема. МИН ҖӘЙНЕ ЯРАТАМ** | **Бурычлар:**1) табигатьтәге җәйге үзгәрешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, билгеле бер ситуациягә туры килгән фигыльләрне сөйләмдә куллануларын активлаштыру, сөйләмдә "бер", "күп" төшенчәләрен ныгыту; 2) балаларның игътибарын, диалоглы сөйләмен, уңай хис-кичерешләрен, кабул итүләрен | Туган телдә сөйләшәбез |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | үстерү;3) табигатькә сакчыл караш тәрбияләү.**Җиһазлар:** күбәләк, бал корты, чебен, черки рәсеме, урман, елга буе, яшелчә бакчасы сурәтләнгән рәсемнәр. | |

**“Матур әдәбият уку”** юнәлеше. Максат: әйләнә-тирә белән таныштыру; әдәби телне үстерү; сүз сәнгатенә тарту.

| Ай исеме | Оештыру эшчәнлеге | Бурычлар | Кулланылган әдәбият |
|---|---|---|---|
| сентябрь | **Тема. З. ГОМӘРОВАНЫҢ “ УЛ ШУҢА КЕЧКЕНӘ” ДИГӘН ШИГЫРЕН УКУ** | **Бурычлар**1)балаларның шигъри әсәр белән таныштыру, эчтәлеген тыңлый һәм аңлый белү осталыгын формалаштыру, аерым сүзләрне, фразаларны тәрбияче артыннан кабатлау мөмкинлеге бирергә, сүзлекне активлаштыру; балаларның кабул итүләрен, игътибарын, хәтерен, хәрәкәтләрен үстерү; әсәргә кызыксыну, сәламәт яшәү теләге тәрбияләү. **Җиһазлар:** курчак уенчыгы, “ Курчак” җырының аудиоязмасы ( М.Бикбова сүзләре һәм көе). | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема. Э.МӨЭМИНОВАНЫҢ “ ҮЗ ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШӘ” ШИГЫРЕН УКУ** | **Бурычлар:**балаларны Э. Мөэминованың “ Үз телендә сөйләшә” дигән шигыре белән таныштыру, тәрбияче артыннан аерым сүзләрне кабатларга өйрәтү;кабул итүләрен, игътибарын, фикерләүләрен, туган телгә кызыксынуларын үстерү;туган телгә мәхәббәт һәм аны өйрәнү теләге тәрбияләү.**Җиһазлар:** “Туган тел” җырының аудиоязмасы ( Г. Тукай сүзләре) | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема. Ә. БИКЧӘНТӘЕВАНЫҢ “ТУП” ШИГЫРЕН ЯТТАН ӨЙРӘНҮ** | **Бурычлар:**1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга һәм сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү, сорауларга җавап бирүдә күнектерү;2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, хәтерен, интонацияле сөйләмен үстерү;3) балаларда кайгыртучанлык, бергә шөгыльләнү теләге тәрбияләү.**Җиһазлар:** Әминә исемле курчак, бала санынча кәрҗингә салынган кечкенә туплар, таз белән су | Туган телдә сөйләшәбез бит |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Тема. Ә. ЕРИКӘЙНЕҢ “КӨЗ” ШИГЫРЕН ЯТТАН ӨЙРӘНҮ** | **Бурычлар:**1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга, аны истә калдырырга һәм сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү, шигырьдәге килде, саргайды, шиңде, сибелде фигыльләре хисабына сүзлекне баету;2) балаларның кабул итуләрен, хәтерен, күзәтүчәнлекләрен, игътибарлыкларын үстерү;3) көзге матурлыкка соклану хисләре тәрбияләү.**Җиһазлар:** көзге урман сурәтләнгән картина. “Яфрак бәйрәме” җырының аудиоязмасы. *(Р. Еникаева көе, Л. Лерон сүзләре).* | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| октябрь | **Тема М. ФӘЙЗУЛЛИНАНЫҢ “КӨЗГЕ ЯҢГЫР” ШИГЫРЕН УКУ.** | **Бурычлар:**1) шигырьнең эчтәлеге белән балаларны таныштыру, тәрбияче сөйләмен аңлау осталыгын камилләштерү, шигырьнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү, чикләнгән мәйданда йөгерүдә күнектерү;2) кабул итүләрен, игътибарны, тәрбияче сигналы буенча йөгерү һәм зонтик астына качу осталыгын үстерү;3) шигъри әсәргә кызыксыну, тыңлаучанлык тәрбияләү.**Җиһазлар:** ковроград. Кояш, болыт, яңгыр, апа, сеңелнең контурлы сурәтләре. Зур зонт. | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема. “БАШ БАРМАК...”ШИГЪРИ ӘСӘРЕН УКУ** | **Бурычлар**.1) шигъри әсәрнең эчтәлеге белән таныштыру; бармак атамаларын истә калдыру,бармак уеннарына өйрәтү;2) балаларның кабул итүләрен, хәтерне, интонацияле сөйләмен, бармак хәрәкәтләрен үстерү;3) халык аваз иҗатына хөрмәт, организм әгъзаларына сакчыл караш тәрбияләү | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема. Ә.БИКЧӘНТӘЕВАНЫҢ “ БӘТИЛӘР” ШИГЫРЕН УКУ** | 1) шигырнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү һәм тирәнәйтү, сорауларга җавап бирүдә, аваз ияртемнәрен кабатлауда күнектерү;2) балаларның кабул итүләрен, сүзлеген, сенсор музыкаль ишетү сәләтен үстерү.3) йорт хайваннарына карата кайгыртучанлык хисләре тудыру.**Җиһазлар:** бәрән уенчыгы яки бәрән рәсеме, йон, йоннан бәйләнгән бияләй, шәл, оекбаш, киез итекләр,” | Туган телдә сөйләшәбез бит |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Бәтиләр” җырының ( Ә.Бакиров музыкасы, Ә.Бикчәнтәева сүзләре) аудио язмасы. | |
| | **Тема. Ш. МАННУРНЫҢ “ЯРАТАМ” ШИГЫРЕН ЯТТАН ӨЙРӘНҮ.** | **Бурычлар:**1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, тәрбияче сорауларына җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү, сүзлекне активлыштыру һәм баету, гомумиләштерә торган сүзне сөйләмдә куллануда күнектерү;2) шигъри әсәрне яттан сөйләү теләге, кабул итүне, хәтерне, игътибарны үстерү;3) гаиләгә карата хөрмәт, туганлык хисләре тәрбияләү.**Җиһазлар:** гаилә сурәтләнгән картина:. әти, әни, ике малай (абыйлы-энеле) һәм бишектәге кечкенә кыз. | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| ноябрь | **Тема. “ӘЛЛИ БӘЛЛИ ИТӘРГӘ ...” БИШЕК ҖЫРЫН УКУ** | **Бурычлар:**1) бишек җырының эчтәлеге белән таныштыру, тәрбияче сөйләмен аңлау сәләтен камилләштерү, сөйләмдә” тирбәтергә” фигылен куллана белергә өйрәтү;2) кабул итүне, игътибарны, конкрет образлы фикерләүне үстерү;3) сөйләм этикетының гади формулаларын (“Алсу йокың тәмле булсын!”) һәм бишек җырларын тормышта куллана белү теләге тәрбияләү.**Җиһазлар:** елый торган курчак, бишек | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема. Н. КАШТАННЫҢ “ БЕЗНЕҢ СЫЕР” ШИГЫРЕН УКУ.** | **Бурычлар:**1) шигырьнең эчтәлеген балаларга аңларга ярдәм итү, тәрбияче сөйләмен аңлау осталыгын камилләштерү, кайбер сүзләрне ( мөгери, китер,йөгер,му – уу, су – у-у) әйтеп җибәрү, ү аваз ияртемнәрен әйтүдә күнектерү;2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен үстерү;3) йорт хайваннарына карата сакчыл караш,кайгыртучанлык тәрбияләү.**Җиһазлар:** сыер рәсеме | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема. Җ. ТӘРҖЕМАНОВНЫҢ “ ҮЗЕН БИК ЧИСТА ЙӨРТӘ” ШИГЫРЕН УКУ.** | **Бурычлар:**1) балаларны яңа шигырь белән таныштыру, аның эчтәлеген аңлап, кабул итүләрен камилләштерү, сорауларга төгәл итеп җавап бирүдә күнектерү;2) кабул итүләрен, игътибарын, хәрәкәтләрен, фикерләүләрен үстерү;3) балаларда пөхтә һәм чиста йөрү теләге | Туган телдә сөйләшәбез бит |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | тәрбияләү.**Җиһазлар:** песи уенчыгы | |
| | **Тема. “ОЛЫГА – УТЫН ЯРЫРГА” БАРМАК УЕНЫ** | **Бурычлар:**<br>1) фольклор әсәрләренә кызыксыну уяту; шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтүне дәвам итү;.2) балаларның эмоциональ сферасын үстерү;3) нәфис сүзгә мәхәббәт тәрбияләргә**Җиһазлар:** М. Андерьянова көе һәм сүзләренә язылган “Нәниләр” жырының аудиоязмасы | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| декабрь | **Тема. Р. ВӘЛИЕВАНЫҢ “СҮЗ ТЫҢЛАУЧАН БУЛЫГЫЗ” ШИГЫРЕН УКУ** | **Бурычлар:**1) балаларны Р.Вәлиеваның шигыре белән таныштырырга, сорауларга җавап бирү осталыгын активлаштырырга, “Җиһаз” сүзен актив сүзлеккә кертергә. Җиһаз атамаларын таный һәм атый белүләрен формалаштырырга.2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын , хәтерен, диалогик сөйләмен, классификацияли белүләрен үстерү;<br>3) куанычлылык, тыйнаклык, кунакта үз – үзеңне тота белү кагыйдәләрен тәрбияләргә.<br>**Җиһазлар:** Алсу курчак, курчак йорты, курчак йорты өчен җиһаз. | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема. Б.РӘХМӘТНЕҢ “ КЫШ БАБАЙ” ШИГЫРЕН ЯТТАН ӨЙРӘНҮ.** | **Бурычлар:**1) шигъри әсәр белән таныштыру, тәрбияче ярдәме белән шигырьне яттан сөйләү омтылышын хуплау, сорауларга текст сүзләре белән җавап бирүдә күнектерү;2) балаларның кабулитүләрен ,хәтерен, сүзлеген,игътибарын, хәрәкәтләрен үстерү;3) балаларда Кыш бабайга, Яңа ел бәйрәменә карата уңай эмоциональ хисләр тәрбияләргә.<br>**Җиһазлар:** Кыш бабай уенчыгы | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема. Һ.ТАКТАШНЫҢ “ЛӘЙЛӘ” ШИГЕРЕН УКУ** | **Бурычлар:**1) шигъри әсәрнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга дөрес җавап бирә белү осталыгын камилләштерү, тәрбияче артыннан аерым сүзләрне, фразаларны кабатларга мөмкинлек бирү, ел фасыллары турындагы белемнәрен тирәнәйтү;2) балаларның кабул итүләрен, хәтерен, игътибарын, хәрәкәтләрен үстерү;3) кышкы табигатькә соклану хисе, башка кешеләрнең кичерешләрен аңлауны тәрбияләү.**Җиһазлар: ч**ана уенчыгы, курчак. | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема. Җ. ДӘРЗАМАНОВНЫҢ “АЛМАЗ”** | **Бурычлар:**1) балаларны Җ. Дәрзамановның шигыре белән таныштыру, тәрбияченең сорауларына | Туган телдә сөйләшәбез |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **ШИГЫРЕН УКУ.** | җавап бирүдә күнектерү, җыр тыңлаганда активлык күрсәтергә өйрәтү;2) кабул итүләрен, игътибарны, сүзлекне, музыкаль ишетү сәләтен үстерү;3) дөрес киенү теләге һәм шигырьләргә карата кызыксыну тәрбияләү.**Җиһазлар: а**ю уенчыгы *(ул дөрес киенмәгән)*, “Алмаз” җырының аудиоязмасы *(Р. Еникеев көе, Җ. Дәрзаманов сүзләре).* | бит |
| январь | **Тема. Ә. БИКЧӘНТӘЕВАНЫҢ “САЛКЫН САФ ҺАВА” ШИГЫРЕН ЯТЛАУ.** | **Бурычлар:**1) балаларны шигъри әсәрнең эчтәлеге белән таныштыру, кышкы табигать турындагы белемнәрен тирәнәйтү, шигъри текстны истә калдырырга ярдәм итү;2) сорауларга җавап бирү, әдәби сөйләм осталыгы үстерү;3) шигъри әсәргә карата кызыксыну тәрбияләү.**Җиһазлар:** мольберт,шигырьнең эчтәлеге сурәтләнгән картина, күңелле бию көе (аудиоязма), кар бөртекләре | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема. З. ТУФАЙЛОВАНЫҢ “ ШОФЕР БУЛАМ” ДИГӘН ШИГЫРЕН УКУ.** | **Бурычлар:**1) балаларны шигырьнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга җавап бирә белүләрен камилләштерү, сүзлекне баету һәм активлаштыру;2) балаларның кабул итүләрен, игътибарларын, конкрет - образлы фикерләүләрен үстерү;3) шофер хезмәтенә карата кызыксыну һәм юл йөрү кагыйдәләрен үтәү теләген тәрбияләү.**Җиһазлар:** тылсымлы капчык, машина уенчыгы, шигырь эчтәлегенә туры килгән рәсем. С. Низаметдинов көе, Ф. Рәхимголыва сүзләренә “ Шофер” җыры аудиоязмасы | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема. Ә. ИСХАКНЫҢ “ГҮЗӘЛ” ШИГЫРЕН УКУ.** | **Бурычлар:**1) шигырьнең эчтәлеге белән балаларны таныштыру, тәрбияче сорауларына аңлы рәвештә җавап бирү осталыгын камилләштерү, җырның сүзләренә туры килә торган хәрәкәтләр ясарга өйрәтү;2) балаларның кабул итүләрен, хәтерен, игътибарын, диалогик сөйләмен, хәрәкәтләрен үстерү;3) балаларда культура – гигиеник күнекмәләрен тәрбияләү.**Җиһазлар:** Гүзәл курчагы, М. Бикбова сүзләре һәм көенә язылган “Курчагым” җырының аудиоязмасы. | Туган телдә сөйләшәбез бит |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Тема. Д. АППАКОВАНЫҢ “РӨСТӘМ” ӘСӘРЕН УКУ.** | **Бурычлар:**1) чәчмә әсәрнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, тәрбияченең сорауларына җавап бирүдә күнектерү;2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, диалоглы сөйләмнәрен үстерү;3) әдәплелек тәрбияләү.**Җиһазлар:** фланелеграф. Самовар, өстәл, конфетлар, сумса, карбыз, алманың контурлы сурәтләре. | Туган телдә сөйләшәбез |
| февраль | **Тема.** “**ЧӘБӘК-ЧӘБӘК ӘБКӘСЕ...” ЮАТКЫЧЫН УКУ** | **Бурычлар:**1) балаларны юаткычның эчтәлеген күрсәтмәлектән башка гына тыңлый белү осталыгын формалаштыру; юаткычның кайбер сүзләрен тәрбияче артыннан кабатларга мөмкинлек бирү;2) балаларның кабул итүен, игътибарын, кул һәм гәүдә хәрәкәтләрен үстерү;3) татар халык аваз иҗатына карата кызыксыну, әниләргә карата хөрмәт тәрбияләү.**Җиһазлар:** кәрҗин *(*җиләк салу өчен*).* | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема. З. ТУФАЙЛОВНЫҢ “ӘНИ СҮЗЕ” ШИГЕРЕН ЯТЛАУ.** | **Бурычлар:**1) балаларны шигырь белән таныштыру, истә калдыру, тәрбияче биргән сорауларга шигырь сүзләре белән җавап бирергә өйрәтү;2) балаларның кабул итүләрен, хәтерен, сәнгатьле сөйләмен, сенсор сәләтләрен, уңай эмоцияләрен үстерү;3) әниләргә карата мәхәббәт тәрбияләү | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | Тема. Г. НӘБИУЛЛИНАНЫҢ “ӘНИГӘ БУЛЫШАМ” ШИГЫРЕН УКУ. | **Бурычлар:**1) балаларны Г. Нәбиуллинаның шигыре белән таныштыру, бирелгән сорауларга җавап бирергә өйрәтү;2) кабул итүләрне, игътибарны, хәтерне, диологик сөйләмне, кулларның вак маторикасын үстерү; 3) тырышлык, әниләргә ярдәм итү теләге, пөхтәлек тәрбияләү.<br>**Җиһазлар:** Әмир исемле курчак; балаларга җитәрлек санда уенчык күлмәкләр һәм ботинкалар моделе; энә белән җепләр | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема. “ТӨЛКЕ, КУЯН ҺӘМ ӘТӘЧ” ӘКИЯТЕН СӘХНӘЛӘШТЕРҮ** | **Бурычлар:**1) балаларны яңа әкият белән таныштыру, әкият сюжетының башын күзәтергә өйрәтү, әкият геройларының характерлы билгеләренә, хәрәкәтләренә балаларның игътибарын җәлеп итү;2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, хәтерен, хәрәкәтләрен, сөйләм активлыгын үстерү;3) балаларда халык әкиятләренә кызыксыну тәрбияләү.<br>**Җиһазлар:** өстәл театры: әтәч, куян, төлке, үгез, аю, эт. | Туган телдә сөйләшәбез бит |

| | | | |
|---|---|---|---|
| март | **Тема.** **Л. ТОЛСТОЙНЫҢ “ӨЧ АЮ” ӘКИЯТЕН УКУ** | **Бурычлар**:1) күләмебуенча зур булган әкиятне игътибар белән тыңларга һәм аңларга өйрәтү, балаларга әкиятне, алар кызның язмышы өчен дулкыналырлык һәм чишелешенең яхшы тәмамлануына шатланырлык итеп сөйләү, сүзлекне активлаштыру; 2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, фикерлүләрен үстерү;3) балаларда интонацияле сәнгатьле сөйләм, кеше хәлен аңлый белүләрен, әкиятләргә кызыксынутәрбияләү.**Җиһазлар**: фланелеграф,әкият персонажларының (кыз,өч аю), өйнең, урманның, өч савыт, өч кашык, өч кроватның контурлы рәсемнәре, аш бүлмәсенең, йокы бүлмәсенең рәсемнәре. | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема.** **Л. ТОЛСТОЙНЫҢ “ ӨЧ АЮ” ӘКИЯТЕН СӨЙЛӘҮ** | **Бурычлар:**1) күләме буенча зур булган әсәрне игътибар белән тыңларга һәм аңларга өйрәтү, эчтәлеген аңлауларына ирешү, башкаларның эмоциональ халәтен аңлый белергә өйрәтү;2) игътибарны, диалоглы сөйләшүне,кабул итүне,хәтерне, интонацияле, сәнгатьле сөйләмне үстерү;3) җиһазга карата сак караш, әйләнә тирәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен тәрбияләү.<br>**Җиһазлар:** фланелеграф, өч аюның контурлы сүрәте. | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема.** **“ТӨЛКЕ, КУЯН ҺӘМ ӘТӘЧ” ӘКИЯТЕН СӨЙЛӘҮ** | **Бурычлар:**1) рус халык әкиятен балаларның исләренә төшерү, сюжетның үсеше артыннан күзәтү, әкиятнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирерә өйрәтү;2) балаларның кабул итүләрен, хәтерен, игътибарын, фикерләвен, интонацияле сәнгатьле сөйләмне үстерү;<br>3) балаларда кеше хәленә кердә белүчәнлекне, кайгыртучанлык, ярдәм итүне, бер-берсенә карата игътибарлылык, дуслык тәрбияләү **Җиһазлар:** әкият персонажларының курчаклары, балалар санынча әтәч битлекләре, бер төлке битлеге. | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| апрель | **Тема.** **Д. ГАРИФУЛЛИННЫҢ “ ТАВЫКЛАР ҺӘМ ТАҺИР” ШИГЫРЕН УКУ** | **Бурычлар:**1) шигъри әсәр белән таныштыру, йорт кошлары турындага белемнәрне тирәнәйтү, сорауларны аңлап ,дөрес җавап бирдә күнектерү, аваз ияртемнәре әйтелешен кабатлау, бер һәм күп төшенчәләрен ныгыту;<br>2) балаларның кабул итүләрен, хыял итүләрен, игътибарын, тәрбиячене ишетә белү осталыгын, кул хәрәкәтләрен, иҗадилыкларын үстерү;3) балаларда йорт кошларына карата кайгыртучанлык ,үзләре башкарган эшкә шатлана | Туган телдә сөйләшәбез бит |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | белүләрен тәрбияләү **Җиһазлар:** чебиләр йөри торган, тавыкларны ашатучы малай төшерелгән картина, балалар санынча кечкенә ак шарлар яки чикләвекләр (грецкий), алтын төсендәге фольга кисәкләре, кәрҗин. | |
| | **Тема. Р. БАТУЛЛАНЫҢ " ЕЛАК ӘТӘЧ" ӘСӘРЕН УКУ** | **Бурычлар:**1) әкиятнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга дөрес һәм аңлап җавап бирүдә күнектерү, төрле орлыкларны (бодай, дөге) аера белүләрен формалаштыру;<br>2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын үстерү, кул чукларының вак мускулларын, сөйләмнәрен активлаштыру;<br>3) тешләрне саклау,аларны карау теләге ,кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү.<br>**Җиһазлар:** томшыгы бәйләнгән әтәч уенчыгы; бодай, дөге салынган савыт һәм һәрбалага икешәр тәлинкә (берсенә бодай һәм дөге бөртекләре салынган,ә икенчесе аларны аерып салу өчен | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема. Б. РӘХМӘТНЕҢ "ЯЗ" ШИГЫРЕН ЯТЛАУ** | **Бурычлар**:1) балаларны Б. Рәхмәтнең "Яз" шигере белән таныштыру, истә калдырырга ярдәм итү, эчтәлегенә туры китереп, сорауларына җавап бирергә өйрәтү, яз турындагы белемнәрне киңәйтү;<br>2) кабул итүне, игътибарны, хәтерне, сөйләмнең интонацияле сәнгатьле үстерү;<br>3) шигырьгә язгы табигатькә карата кызыксыну тәрбияләү.<br>**Җиһазлар:** сыерчык сүрәтләнгән картина. Башка җылы яктан кайткан кошлар сүрәтләнгән картина. Кош битлекләре. | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема Х.ВАХИТНЫҢ "УҢГАН СЫЕРЧЫК" ШИГЫРЕН УКУ** | **Бурычлар:**1) балаларны шигырь белән таныштыру, тәрбияче сорауларның шигырь сүзләре белән җавап бирүне ныгыту, музыка астында түгәрәктә бер – берсенә комачауламый йөрүләрен формалаштыру, кошлар турындагы белемнәрне киңәйтү;<br>2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, диалогик сөйләмен, хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) балаларда туган якка мәхәббәт, сыерчыкларга карата кызыксыну тәрбияләү.<br>**Җиһазлар:** сыерчык битлеге, фланелеграф, чыпчык, карга, күгәрчен, сыерчыкның контурлы сүрәтләре; Г. | Туган телдә сөйләшәбез бит |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Латыйпов сүзенә Ш. Мәҗитов көенә язылган “ Кошлар килде” җырының аудиоязмасы | |
| май | **Тема .”ТИЛГӘН” ЭНДӘШЕН УКУ** | **Бурычлар:**1) балаларны күләме буенча зур булмаган шигъри әсәрне тыңларга һәм аңларга өйрәтүне дәвам итү, шигырьдәге аерым сүзләр һәм фразалар хисабына сүзләрне киңәйтү, сүзләрне истә калдырырга ярдәм итү, кошлар (тилгән) турындагы белемнәрне тирәнәйтү;2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, конкрет – образлы фикерләвен үстерү;3) балаларда дөрес интонацияле сөйләм тәрбияләү.**Җиһазлар:** тилгән төшерелгән картина, балалар санынча чеби уенчыклары салынган тартма, тавык битлеге, тавык уенчыгы | Туган телдә сөй-ләшә без бит |
| | **Тема. АЮ БЕЛӘН ХАТЫН ӘКИЯТЕН УКУ.** | **Бурычлар:**1) әкиятнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга аңлап җавап бирү осталыгын камилләштерү, сүзлекне киңәйтү, активлаштыру. [3] авазын ачык әйтүдә күнектерү;2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, фикерләүләрен, чикләнгән бүлмәдә йөгерүләрен үстерү;3) халык авыз иҗатына мәхәббәт, мәрхәмәтлелек, кеше хәленә керә белүчәнлек тәрбияләү.**Җиһазлар:** бал кортлары, аю битлекләре. Аягы бәйләнгән аю уенчыгы.Урак рәсеме | Туган телдә сөйләшәбез бит |
| | **Тема. Җ. ТӘРҖЕМАНОВНЫҢ “ КИКРИКҮК” ШИГЫРЕН УКУ.** | **Бурычлар:**1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, сорауларны аңлау осталыгын камилләштерү, тема буенча сүзлекне баету һәм активлаштыру, тәрбияче артыннан аерым фразаларны кабатлауда һәм аваз ияртемнәрен дөрес әйтүдә күнектерү;2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын диалогик сөйләм осталыгын, вакыт өлешләрендә ориентирлануларын, бармак хәрәкәтләрен үстерү;3) балаларда әдәби әсәргә кызыксыну тәрбияләү.**Җиһазлар:** кычкыра торган әтәч уенчыгы, казлар, үрдәкләр, тавыклар, әтәч төшерелгән рәсем | Туган телдә сөйләшәбез бит |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Тема. М. МАЗУНОВНЫҢ “КӘҖӘ” ШИГЫРЕН УКУ** | **Бурычлар:**1) шигырьнең эчтәлеге белән балаларны таныштыру, сорауларга бәйләнешле итеп җавап бирүдә, аваз ияртемен дөрес әйтүдә күнектерү;2) балаларның кабул итүен, игътибарын, фикерләвен, бәйләнешле сөйләмен, кул хәрәкәтләрен үстерү;3) кәҗәгә карата уңай караш, кайгыртучанлык тәрбияләү.**Җиһазлар:** фланелеграф, кәҗә белән кәбестәнең контурлы сурәтләре. | Туган телдә сөйләшәбез бит |

## Нәфасәти үсеш өлкәсе.

**“Сынлы сәнгать ” юнәлеше**. Максат: балаларда сынлы сәнгатькә карата кызыксыну уяту, мөстәкыйльлекне хуплау; продуктив эшчәнлекне үстерү (рәсем, әвәләү, кисеп ябыштыру) Авторлар: Р. М. ЗИННАТОВА, Л. Ә. ГАРӘЕВА, А. Г. ЗВОРЫКИНА(**СУРӘТЛӘҮ ЭШЧӘНЛЕГЕ ҺӘМ КОНСТРУКЦИЯЛӘҮ)**

| **Ай исемнәре** | **Эш төрләре, шөгыльләр темасы** | **Бурычлар** | **Кулланмалар** | **Җиһазлау** |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь | Әвәләү: «Әвәләргә өйрәнәбез | • Балчыкның үзлекләре белән (йомшак, кисәкләргә аерырга, әвәләргә мөмкин) таныштыруны дәвам итү.<br>• Балаларда әвәләү шөгыленә кызыксыну тәрбияләү.<br>• Балаларны пөхтә, матур эшләргә өйрәтү. | Балаларның игътибарын балчыкның үзгәрүчән формасына юнәлтү, әвәләү формасын күрсәтү, шәхси булышу. | Пластилин (балчык), әвәләү өчен такта, салфетка |
| | Әвәләү:«Аюга күчтәнәч» | Балаларны балчык йомарла-мыннан кечерәк кисәкне аерып алырга, балчыкны кул белән ту-рыга тәгәрәтеп әвәләргә өйрәтүне дәвам итү. Балаларда сюжетлы уеннар уйнау теләген булдыру. Балаларда бер-берсенә ярдәм итү теләген үстерү. Балаларны Р. Харисның «Лап-лап» | Р. Харисның «Лап-лап » ши-гырен уку, анализ ясау. Аңлату, иллюстрацияләр карау, мактау, тулы күрсәтмә бирү, мөстәкыйль эш, бәя бирү, әңгәмә алымнарын куллану. | Балчык яисә пластилин, поднос, әвәләү өчен такта, салфетка, кәнфит кәгазьләре, аю уенчыгы, төрле формадагы кәнфитләр. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | дигән шигыре белән таныштыру | | |
| | Рәсем: «Яңгыр» | Балаларны традицион булмаган рәсем ясау (бармак белән) техника-сы белән таныштыру.Штрих, буяуларны салмак төшерергә өйрәтү. Рәсем ясау шөгыленә кызыксыну уяту | Балаларны В. Хәйруллинаның «Яңгыр» дигән шигыре белән та-ныштыру. Табышмак, уен алымы аркылы шөгыльгә кызыксыну уяту, һавада кул хәрәкәтләрен кабатлау, «пассив хәрәкәт», «кулга кул» алымнарын куллану, тулы күрсәтмә һәм аңлатма бирү аркылы балаларның формалаштырулы хәрәкәтен дәвам итү. | Зәңгәр төстә гуашь, **А4** форматын-да болытлар ябыштырылган бит, салфетка, иллюстрацияләр, уен өчен кулчатыр. |
| | Рәсем: «Тылсымлы таякчык» | Балаларны карандаш (флома-стер) белән таныштыру һәм алар белән кулланырга өйрәтү, рәсем ясау барышына һәм нәтиҗәсенә кызыксыну уяту.Балаларны тыңларга һәм гади күнекмәләрне эшләргә өйрәтү. Балаларны төс һәм форма белән таныштыруны дәвам итү.Балаларны рус шагыйре Н.В. Беловның «Карандаш» дигән ши-гыре белән таныштыру | Н.В. Беловның «Карандаш» шигырен уку. Сорау, мактау, бәя бирү алымын куллану. | Карандаш (фломастер), А4 форматында ак төстә битләр, иллюстрацияләр, хайван уенчы-гы, төрле төстәге әләмнәр. |
| | Төзү: «Мияубикәгә сукмак» | Төзү осталыкларын камилләштерү. Төзелештәге төп детальләрне (пластилин) аера һәм әйтеп бирә белергә өйрәтү. Балаларның үз эшләгән эшләренә шатлык хисе тәрбияләү. | Балаларны К. Ушинский «Мияубикә» дигән әсәре белән таныштыру«Мияу бикә» әсәре аша балалар-да уйнау теләге булдыру. Үрнәк эшне карау, курсәтү алымнарын | Мәче уенчыгы, һәрбер балага кирпеч. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | куллану,балаларның эшенә нәтиҗә ясау. | |
| | Төзү:«Йорт хай-ваннары өчен киртә» | Кирпич, пластинаны үзара тыгыз яки ара калдырып урнаш-тырып, вертикаль юнәлештә бер рәт түгәрәк, дүртпочмаклык ясап төзергә;Төп корылма исемен ныгыту-кирпич.Эш барышында балаларда сабырлык, пөхтәлек хисен тәрбияләү. Хайваннарга карата мәхәббәт тәрбияләү.Балаларның хайваннар дөньясы турындагы белемнәрен ныгыту. | Хайваннарның яшәү шартла-ры турында, уен алымы аша күзаллау, формалаштыру, (уен«Хайваннарны чакыр»), Образлар белән танышканда конструктив осталыкларын арттыру. Хайваннарга сакчыл караш тәрбияләү, мактау. | Йорт хайваны уенчыгы, кирпичләр. |
| | Кисеп ябыштыру: «Чебиләр өчен койма» | Тәрбияче әзерләп биргән бертөрле, төрле формадагы һәм зурлыктагы 2-3 кисәктән торган предметларның сурәтләрен кәгазь битенә тезеп чыгарга һәм ябыш-тырырга өйрәтү.Җилемне пумалага кирәк кадәр генә алырга, әзер формаларга җилемне клеенка өстендә сы-ларга, чүпрәктән файдаланырга өйрәтү.Балаларда мөмкин кадәр пөстә эшләү теләген үстерүБалаларны «Төлке һәм тавык » уены белән таныштыру. | **Аңлату**, иллюстрацияләр карау, **мактау, тулы** күрсәтмә бирү, **мөстәкыйль** эш, бәя бирү, әңгәмә алымнарын куллану. Шигырь **уку капшап** карау, дөрес итеп бәя **бирергә** өйрәтү | Чеби уенчыгы, төзү материалы, Аб форматында ябыштырылган чеби үрнәге, җилем, пумала, |
| | Кисеп ябыштыру: «Парк сукма-кларында керпе эзләре | Балаларга яфракларны төсләренә карап аралаштырып куярга өйрәтү.Җилемне пумалага кирәк кадәр генә алырга, әзер формаларга җилемне клеенка өстендә сы-ларга, чүпрәктән файдаланырга өйрәтү.Балаларда туган якларына мәхәббәт, ачык матур күренешләргә | Нәфис сүзләр кулланып көз турында әңгәмә үткәрү. Иллюстрацияләр карау. Ябыштыру, тезү алымнарын күрсәтү. | «Ел фасыллары» сериясеннән «Көз» картинасы, зәңгәр күк төстәгә А4 фарматның **1**/3 зур-лыгында тасма, көзге яфраклар (әзер |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | кызыксыну уяту. | | формалар), клеенка, пума-ла, җилем. |
| октябрь | Әвәләү: «Тылсымлы таякчык | Балаларны балчык йомарла-мыннан кечерәк кисәкне аерып алырга, балчыкны кул белән ту-рыга тәгәрәтеп әвәләргә өйрәтүБалаларда уйнау теләге булдыру.Әвәләү барышында пөхтәлек тәрбияләү. Балаларның сүзлек запасын баету: тигез,туры. | әвәләү алымнарын автоматизасияләү**,** нәтиҗә ясау, **мөстәкыйль** эш, бәя бирү, әңгәмә **алымнарын** куллану | Балчык яисә пластилин, поднос, әвәләү өчен такта, салфетка, санау таякчыгы |
| | Әвәләү «Клиндер | Балчыкны турыга әвәләгәндә барлыкка килгән форманы бөҗра ясап тоташтыру.Балаларда уйнау теләген үстерүБалаларда төрле халык мәдәниятына, сәнгатенә соклану хисе тәрбияләү.<br><br>Рус халык шигырьләрен уку. | Әвәләү алымнарын ныгыту, мактау, балаларның эшләренә игътибар бирү, әвәләү процессында мөстәкыйль эш эшләү. | Балчык яисә пластилин, поднос, әвәләү өчен такта, салфетка, клиндерләр өчен ике җеп, татар халык киеменнән курчак |
| | Рәсем: «Сукмак буйлап | Төрле зурлыктагы эзләрне та-нырга һәм тимгел-темгел таплар-ны ритмик рәвештә төшерергә өйрәтү.Балаларда пумаланы дөрес тотарга, пумала белән эшләү тех-никасын өйрәтүне ныгыту.Балаларда пөхтәлек тәрбияләү | Хәрәкәтле уеннар оештыру. **һавада** куллар белән хәрәкәтләр **ясау,** иллюстрацияләр карау **мактау,** тулы күрсәтмә бирү, мөстәкыйль эш, бәя бирү, әңгәмә алымнарын куллану | Кара төстә гуашь, А3 һәм **А4** форматында битләр, пумала, сал-фетка, иллюстрациия . |
| | Рәсем: «Тесле тасмалар», «Филимонов уенчыгы» | Төрле юнәлештәге туры сызы- клар үткәрергә, предметка туры килгән төсне сайлап алырга өйрәтү. Пумала белән сызыклар-ны өстән аска таба юнәлтергә (сулдан уңга).Пумала юу осталыгын ныгыту, пумала белән пөхтә куллана белергәБалаларда төс һәм ритмны үстерү.Балаларда уенчыкларга карата сакчыл караш уяту. | Уен ситуациясы һәм әңгәмәләр оештыру, һавада кул хәрә-кәтләрен кабатлау. Аңлатма бирү, күрсәтү һәм «кулга кул» алымнарын куллану, рәсем ясау техникасынныгыту | Ике төстә гуашь, **А4** форматын-<br><br>дагы бит (филимон уенчыгы) пумала, банка белән су, салфетка, иллюстрациия |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Төзү: «Манара | Балаларны төзү үзенчәлекләре<br><br>белән таныштыру.Төп төзү детале — шакмак белән таныштыру.Балаларда төрле халыклар мәдәниятына, сәнгатенә соклану хисе тәрбияләү. | Балаларга манараның биек, чы-дам икәнен аңлату, кисәкләрдән төзелгәнлеген күрсәтү. Сөембикә, Спас, Пизан манараларын иллюстрацияләрдә күрсәтү | Һәр балага шакмаклар, төрле манарлар белән фотоиллюстрацияләр |
| | Төзү:<br><br>«Уенчыклар өчен тартма» | Балаларны төп төзү детале - кирпич белән таныштыру.Кирпичләрне терәп куеп, уен-чыклар тирәли тоташтырырга өйрәтү.Балаларны тыңларга һәм гади күнекмәләрне эшләргә, эшнең<br>нәтиҗәсен күрүдән шатлак хисе уяту. | Нәфис суз аша балаларда кызык-сыну уяту, уен, үрнәк эшне ка-рау мөстәкыйль эш, тикшерү,бәя бирү алымнарын куллану. | Уенчыклар, һәр балага кирпич |
| | Кисеп-ябыштыру<br><br>Аминәгә ярдәм<br><br>итәбез | Төрле төстәге түгәрәкләрне кәгазьгә таратып салырга өйрәтү.Балаларда ритм һәм төс хисенүстерү.ярдәмчеллелек, пөхтәлек тәрбияләүне дәвам итү. Бикчәнтаеваның «Туп» шигы-рен искә төшерү | Педагогик ситуация куллану, үрнәк эшне карау, аңлатма бирү, тулы күрсәтмә бирү алымнарын куллану. | 2 туп, ак кәгазьдән тасма 15х6 см, кәгазьдән түгәрәкләр, (диаметр 4 см), җилем, пумала клеенка, Таня курчагы. |
| | Кисеп ябыштыру: «Миләш мәрҗәне | Түгәрәк сәйләннәрне сызылган сызыкка пөхтәитепурнаштыру.Балаларда эстетик караш тәрбияләүне дәвам итү.Эш барышында пөхтәлеккә<br><br>өндәү.Туган як халкынын мәдәнияты<br><br>белән таныштыруны дәвам итү. | Бүләк момент кулланып, балалар-да туган якка карата мәхәббәт хисе уяту. (милли күлмәк киеп Алсу курчакның кунакка килүе). Балан-нан төзелгән мәрҗәннәрне | Курчак,миләш ботагы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | карау. | |
| ноябрь | Әвәләү: «Керпе өчен алмалар | Балчыкны кул белән тәгәрәтепәвәләү.Балаларда туган як табигате,хайваннары белән танышу теләген уяту.Балаларда үз эшләренең нәтиҗәсенә шатлану хисе булдыру. | Табышмаклар кулланып көз турында әңгәмә үткәрү, иллюстрацияләр карау, мактау алымын куллану. Әвәләү барышында мөстәкыйль эшләү | Балчык яисә пластилин , поднос, әвәләү өчен такта салфетка, алма муляжы, керпе уенчыгы |
| | Әвәләү: «Пирамид- ка». | Бер үк төрле формадагы берничә өлештән торган гадирәк предметларны тоташтырыга өйрәтү.Балчыкны кул белән түгәрәкләп тәгәрәтергә өйрәтүне дәвам итү; форманың кырыйларын бармак очлары белән чеметеп тотарга өйрәтү.Балаларда пөхтәлек, әвәләргә теләк тәрбияләү. | Уен, мактау, балалар эшләренә игътибар бирү алымнарын кул- лану | Балчык яисә пластилин, поднос, әвәләү өчен такта салфетка, пирамида уенчыгы. |
| | Рәсем: «Курчакның итәген бизибез». | Түгәрәк формадагы предмет-ларны ясарга өйрәтү, рәсем барышында турле төстәге каран- дашлар куллану.Төсләрне аера белергә өйрәтү, (кызыл, сары, яшел, зәңгәр)Рәсемне альбом битендә дөрес урнаштырырга өйрәтү.Балаларда төрле халык, мәдәниятына сәнгатенә соклану хисе тәрбияләү. | Бүләк мизгелен кулану, халык уенчыкларына карата кызык- сыну уяту. Һавада кул белән хәрәкәтләрне кабатлау, күрсәтү алымын киң куллану («пассив хәрәкәт» алымы) Балаларда шат- лык хисе тәрбияләү | Төсле карандашлар (флома- стерлар), бизәлмәгән итәкле дымка курчагы силуэтлары, дымка уенчыгы, дымка уенчыгы тешерелгән иллюстрация ләр |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Рәсем: «Туплар тәгәриләр.». | Балаларда рәсем ясарга кызык-сыну уяту.Балаларда төс һәм ритм хисен<br><br>үстерүне дәвам итү.Ярдәмчеллек тәрбияләү.<br><br>Ә. Бикчәнтәеваның «Туп-туп ту-быбыз» шигырен искә төшерү | Нәфис суз, уен алымынкуллану, ярдәмчелек хисен<br><br>тәрбияләү. Куллар белән һавада хәрәкәтләрне кабатлау, аңлатма<br><br>бирү, тулы күрсәтмә бирү алым-нарын куллану. | Ике төстә гуашь, кәгазьдән тасма, пумала, банка белән су, иллюстрация ләр, төрле зурлык-тагы туплар. |
| | Төзү:<br><br>«Теремкәй очен капка» | Кирпеч һәм пластиналардан вер-тикаль конструкция башкарырга балаларны мәҗбүр итү. Төп төзү детальләрен аера, атый һәм кул-лана белү (кирпич, пластина). Балаларда күмәк эшнең нәтиҗәсен күрүдән шатлану хисләрен уяту. Рус халык әкияте «Теремкәй»не искә төшерү. | Нәфис сүз, уен, үрнәк эш, «Теремкәй» әкиятенә ясалган иллюстрацияләр карау, куллану, рус халык иҗаты белән таныштыру; аңлату, мактау, тулы күрсәтмә бирү, мөстәкыйль эш, бәя бирү, әңгәмә алымнарын куллану | «Теремкәй» әкиятенә иллюстрация һәм хайван уенчыклары, кирпич и пластина. |
| | Төзү:<br><br>«Койма һәм капка» | Кирпич, пластиналарны верти-каль, горизанталь буенча, урнаштырырга өйрәтүне дәвам итү.Төп төзү детальләрен дөрес атый<br><br>белергә өйрәтү — кирпич, пластина. Үзең төзегән корылмаларга иң<br><br>гади анализ ясарга өйрәтү.Балаларны якын этносоциумның әдәбияты һәм мәдәнияты белән таныштыруныдәвам итү. | Үрнәк эшне карау, аңлатма бирү, мөстәкыйль эш, тикшерү, бәя бирү алымнарын куллану | Кирпич, пластина, призмалар, кечкенә уенчыклар (һәр балада) |
| | Кисеп ябыштыру: «Акбайга җылы келәм» | Геометрик фигураларны һәм та-бигый материалларны форма һәм төсләре буенча | Үрнәк эшне карау, аңлатма бирү, мөстәкыйль эш, тикшерү, бәя бирү алымнарын | Келәм, ак бит 15х15 см, үрнәк, җилем, төсле кәгазьдән |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | чиратлаштырырга<br><br>өйрәтү.Балаларда ритм үстерү. Буй, төс исемнәрен (кы-зыл, сары) һәм киңлектә урынны билгеләү осталыгын ныгыту.Җилем белән пөхтә эш итергә йөрәтү. Тәрбиячене тыңларга, эшне нәтиҗәле үтергә осталыкны тәрбияләү. Хайваннарга сакчыл караш тәрбияләүһәм төс хисен. | куллану | тасма (15х2), пумала, җилем, һәр бала-га клеенка, эт уенчыгы |
| | Кисеп ябыштыру: «Матур шарлар | Әзер формаларны төс буенча чиратлаштырып ябыштыруны кунек-<br><br>терергә.Җилем белән эшләүне автомат-лаштыру.Төс (кызыл, сары, зәңгәр, яшел) һәм ритм хисен үстрерү. Балалар-да күмәк эшнең нәтиҗәсен күрүдән шатлык хисе уяту. | Нәфис сүз, иллюстрацияләр ка-рау, әңгәмә, эш тәртибен аңлату. | Шар рәсемнәре, үрнәк эшләр, 20х15 үлчәмендә битләр, пумала, җилем, һәр балага клеенка |
| декабрь | Әвәләү: «Тиен очен чикләвек | Балаларны төрле зурлыктагы түгәрәк формаларны әвәләргә өйрәтүне дәвам итү.Балаларның уйнау теләген арттыру. Балаларда туган як табигатенә сакчыл караш уяту.Хайваннарга карата сакчыл караш тәрбияләү. | Бүләк моменты һәм уен аркылы анализ ясау, әңгәмә тезү Тикшерү, мөстәкыйль эш алымна-рын кулланып, сенсор мәгнәләрен формалаштыру. (зур һәм кечкенә, каты, шома, кытыршык) Уен, нә-фис сүз аша балаларда хайваннар-га карата сакчыл караш тәрбияләү | Балчык яисә пластилин, поднос, әвәләү өчен такта, тастымал, чикләвекләр, тиен уенчыгы |
| | Әвәләү:<br><br>«Әниемә | Бармак белән эшләп, тирәнәй-түче рельеф кулланып эшләнмәне бизәргә өйрәтү.Балчыкны | Педагогик ситуацияләр тудырып балаларны әхлакка | Валчык яисә пластилин, поднос, әвәләү өчен |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | күчтәнәч». | кул белән тәгәрәтеп әвәләү, шарны басып изү.Балчык белән пөхтә эш итү күнекмәләрен ныгыту.Әвәләү күнекмәләрен ныгыту әти-әниләргә карата ихтирам хисе тәрбияләү.Татар шагыйре Газиз Набиуллинның «Әниемә булышам» шигыре белән таныштыру. | өйрәтү. (уен, сорау, әңгәмә, нәфис сүз) Аңлату, мактау, тулы күрсәтмә бирү алымнарын куллану. | такта, тастымал,<br><br>печенье |
| | Рәсем:<br><br>«Тимер юлы» | Балаларга гади предметларны<br><br>ясарга өйрәтү.Туры сызыклар ясау һәм аларны кисештерү алымнарын ныгыту (вертикаль, горизанталь).Кулларның дөрес йөрешен координацияләү. | Ният үстерү очен күңелле миз-гел. Тимер юлын карау (зурлык, урнаштыру) аңлату, мактау, тулы күрсәтмә бирү, мөстәкыйль эш, бәя бирү, әңгәмә алымнарын куллану | А4 форматы, гуашь, пумала, тастымал, су белән банка, паровоз иллюстрация, паровоз уенчыгы |
| | Рәсем: «Агач үсте». | Балаларда агач ясарга кызык-сыну уяту. Туры сызыклардан тора торган гади предметлар ясау күнекмәләрен ныгыту.Балаларның сүзлек байлыгын арттыру: кәүсә — биек, озын, тигез; ботак — нәзек; агачлар — зур, кечкенә.Балаларны эстетик яктан тәрбияләү: балаларның игътибарын туган ик табигатенең гүзәллегенә юнәлтү. Туган як табигатенә сакчыл караш тәрбияләү. | Агачлар турында табышмак-ларга җавап табып, балалар бакчасы участогында агачлар күзәтеп, тикшерү ысулларын күрсәтеп тәрбияче әйберләр турында белемнәрен турыдан-туры тәҗрибәне формалаштыра, аны сурәтләүгә күчерергә өйрәтә. Аңлату, мактау, тулы күрсәтмә бирү, мөстәкыйль эш, әңгәмә, бәя бирү алымнарын куллану. | А4 форматындагы битләр, «Агачлар» иллюстрацияce, гуашь, пумала, салфетка, банка белән су. |
| | Төзү:<br><br>«Урындык» | Кирпич, пластиналарны вер-тикаль, горизанталь буйлап, бер берсенә урнаштырырга өйрәтүне<br><br>дәвам итү.Балалар үзләренә кирәк төзү детальләрен сайлап алуы осталыкларын | Уен алымын куллану, үрнәк эшне кару, балалар авырсынган сорауларга тулы җавап эзләү. әңгәмә,бәя бирү алымнарын | Курчак уенчыгы, шакмак, пла-<br><br>стина, кирпич. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | ныгыту.Уңышлы килеп чыккан корыл-маларга карата шатлык хисе уяту. | куллану. | |
| | Төзү: «Өстәл» | Төзүне тотрыклы иттереп баш-карырга өйрәтергә.Үзләре төзегән өстәлгә иң гади анализ ясарга өйрәтү.Төп төзү детальләрен атый белергә өйрәтү — шакмак, пластина. Үзара мөнәсәбәтләрне формлаш-тыру. Кунакчыллык кагыйдәләрен<br><br>өйрәтү, әдәплелек тәрбияләү. Балаларның активлыгын һәм<br><br>иҗат иркенләген арттыру. Ярдәмчелек күнекмәләрен тәрбияләү. | Уен алымын куллану, өстәл үрнәген карау, өстәл төзү (дурт-пычмаклы пластинадан ясалган) процессын балаларга күрсәтү, мөстәкыйль эш, әңгәмә, бәя бирү алымнарын куллану. | Уенчыклар, Алсу, Алена кур-чаклары, чашка белән чынаяк, кубиклар, пластиналар |
| | Кисеп<br><br>ябыштыру: «Кар бабай һәм чыршы» | Балаларга берничә кисәктән<br>торган сурәтләр ясарга өйрәтү.Геометрик фигураларны,<br><br>төсләрне, формаларын аерырга өйрәтүне дәвам итү.Предметларның охшаш якла-рын табарга өйрәтү | Экскурсия вакытында кар бабай һәм чыршы белән якыннан таны-шу (ак, яшел, зур, кечкенә, аста, өстә, форма), иллюстрацияләр карау; аңлату, мактау, тулы күр-сәтмә бирү | А4 форматындагы зәңгәр төстәге битләр. Киселгән ак түгәрәкләр, яшел өчпочмаклар (терле зур-лыкта), пумала, җилем, һәр ба-лага клеенка. |
| | Кисеп ябыштыру: «Бәйрәм үремнәре» | Әзер кәгазь буйчыгына компо-зицияне һәм төсләрне уйлап әзер формаларны ябыштыру (шарчы-клар, сәйләнләр, шапылдаткач-<br><br>лар)Кисеп ябыштыру күнекмәләрен<br><br>ныгыту.Төс һәм ритм хисен үстерү. Балаларны тыңларга һәм гади күнекмәләрне эшләргә өйрәтү. Эш барышында балаларда сабырлык, пөхтәлек хисен тәрбияләү.Балаларда күмәк | Нәфис сүз куллану, әзерләнгән чыршының зур силуэтын карау аркылы сынлы сәнгатькә теләк үстерү, аңлату, мактау, тулы күрсәтмә бирү, мөстәкыйль эш, әңгәмә, бәя бирү алымнарын куллану | Чыршы силуеты, (тәрбияче та-рафыннан алдан әзерләнгән) кәгазьдән тасма, пумала, җилем,<br><br>һәр балага клеенка |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | эшнең нәтиҗәсен күрүдән шатлак хисе уяту, шатлык хисләре, бәйрәм рухын булдыру. | | |
| январь | Әвәләү: «Аумас курчак» | Балаларны бер формадан торган, әмма төрле зурлыктагы бер-берсенә тыгыз тоташтырып уенчык әвәләргә өйрәтү.Үз эшеңне уйлап башкарырга өй-рәтү. Балаларда төс һәм форма хисе үстерүне дәвам итү.Пөхтәлек, мөстәкыйльлек булдыру. | Шигырь уку, аумас курчак уенчыгын капшап карау, анализ ясау, әвәләү ысулларын карау. Тулы күрсәтмә бирү, мөстәкыйль эш, әңгәмә алымнарын куллану. | Балчык яисә пластилин, поднос, әвәләү өчен такта, тастымал, өстәмә материаллар |
| | Әвәләү: «Теләгән уен-чыкны әвәләү» | Балаларны үз теләкләре буенчауенчык әвәләргә өйрәтү, аның төп өлешләрен күрсәтергә өйрәтүне дәвам итү.Әвәләү ысуларын ныгыту. Үзләренең эшләренә нәтиҗә ясарга өйрәтү. Эш барышында балаларда сабырлык, пөхтәлек хисен тәрбияләү. | Балалар белән уенчыклар турын-да әңгәмә алып бару. Аңлату, мактау, тулы күрсәтмә бирү, мөстәкыйль эш, бәя бирү алым-нарын куллану | Балчык яисә пластилин, поднос, әвәләү өчен такта, тастымал, өстәмә материаллар. |
| | . Рәсем: «Чыршы урманда үсә» | Музыкаль әсәр буенча гади сюҗетлы, төрле зурлыктагы рәсемнәр ясарга өйрәтү.Бармаклар белән ясау күнекмәсен ныгыту.Балаларның активлыгын, иҗат иркенлеген арттыру. Беманның «В лесу родилась ёлоч-ка» җырын искә төшерү. | Чыршы ясау ысулларын искә төшерү. Чыршыны участокта күзәтү, ботакларның юнәлешен һавада билгеләү, нәфис сүз, му-зыкаль әсәр куллану аша ниятке кызыксыну үстерү | А4 форматында соры, (зәңгәр) төстә кагазь битләре, иллюст-рация, гуашь, пумала, тастымал, банка белән су. |
| | Рәсем:<br><br>«Күңеле төшмәс курчак» | Түгәрәк формадан торган пред-метлар ясарга өйрәтү. Компози-ция күнекмәләрен, предметларны кагазь битенең уртасына урнаштырыга өйрәтү.Рәсемне тулылындырырга өйрәтү. Балаларда төс (кызыл, сары, зәң-гәр, яшел), форма (тугәрәк) һәм зурлык, урнаштыру (астан, өстән, яннар буйлап, уртада) белемнәрен үстерүне дәвам | Нәфис сүз, музыкаль әсәр кул-лану аша ниятқә кызыксыну үстерү, ирешү. Аңлату, инди-видуаль булышу, мактау, тулы күрсәтмә бирү, мөстәкыйль эш, әңгәмә, бәя бирү алымнарын куллану. | Аумас курчак уенчыгы, А4 фор-матында битләр, иллюстрация , гуашь, пумала, тастымал, банка<br><br>белән су |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | итү.Балаларның активлыгын һәм иҗат иркенлеген арттыру.П. Энтинаның «Ванька встанька» музыкаль язмасын тыңлату | | |
| | Төзү:<br>«Алсу исем-ле курчакка кәнәфи» | Балаларның белемнәренә таянып, яңа корылмалар төзергә<br>өйрәтү.Төзү күнекмәләрен<br>камилләштерү.Балаларның уенда актив катна-<br>шуларына ирешү. | Йорт җиһазлары иллюстра-цияләрен карау, мактау, тулы күрсәтмә бирү, мөстәкыйль эш, әңгәмә, бәя бирү алымнарын<br>куллану. | Йорт җиһазлары белән иллюстрация ләр, һәр балага уен-чыклар, кирпич, пластиналар. |
| | Төзү:<br>«Бозлы йорт» | Балаларны үрнәк буенча төзәргә өйрәтүне дәвам итү.Үзләре төзегән корылмаларга анализ ясарга өйрәтү. Төзегәндә төрле ысуллар кулла-нырга өйрәтү | Кыш бабайның өен иллюстрацияләрдә карау, аңлату, мактау, тулы күрсәтмә бирү, мөстәкыйль эш, бәя бирү, әңгәмә алымнарын куллану. | Кыш бабайның сихри өе төшерелгән иллюстрация ләр, кирпич, кубиклашакм аклар,призма -р |
| | Кисеп<br>ябыштыру:<br>«Йорт төзибез» | Берничә кисәктән торган пред-метларны кисеп ябыштыруда берләштерергә өйрәтү. Геометрик фигураларны аерырга өйрәтүне дәвам итү (өчпочмак, түгәрәк, шакмакТөсләр белемен ныгыту.Балаларның конструктив күзаллауларын үстерү. | Әкиятнең эчтәлеген кулла-ну, нәфис сүз, конструктив күнекмәләр формалаштыру. Аңлату, индивидуаль булышу, бәя бирү алымнарын куллану. | Кара кәгазь, кәгазьдән төрле фигуралар (өчпочмак, квадрат, турыпочмак), пумала, җилем, салфетка. |
| | Кисеп ябыштыру:<br>«Безнен урам йортлары» | Тәрбияче тарафыннан хәзерләнгән төрле формадагы, зурлыктагы һәм төрле төстәге кисәкләрне кәгазьгә алдан та-ратып салырга һәм билгеле бер тәртиптә тезү күнекмәсен үстерү.Пөхтә эш күнекмәләрен форма-лаштыру.Туган шәһәргә мәхәббәт хисе<br>тәрбияләү | Балалар белән өй иллюстрация-ләрен карау, өйнең өлешләрен билгеләү. Аңлату, мактау, тулы күрсәтмә бирү, мөстәкыйль эш, бәя бирү, әңгәмә, алымнарын куллану. | Казан урамнары иллюстра-циясе, кәгазьдән фигуралар (шакмак, өчпочмак), пумала, җилем, салфетка. |
| февраль | Әвәләү: | Балаларны үзләре ниятләгәнчә әвәләргә өйрәтү.Кирәкле | Әкиятләр, шигырьләр уку, иллюстрацияләрен | Балчык яисә пластилин, поднос, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | «Куянны сыйлыйбыз» | кулланмаларны сайлап алуны ныгыту, әвәләүне ахырына кадәр җиткерү.Балаларда хайваннарга кара-та, ярдәмчелек, мәхәббәт хисләре уяту | карау, әвәләү ысулларын күрсәтү. Аңлату, нәфис сүз, индивидуаль булышу, мактау, тулы күрсәтмә бирү, мөстәкыйль эш, әңгәмә, бәя бирү алымнарын куллану. | әвәләү өчен такта тастымал, өстәмә материаллар, куян уенчы- гы. |
| | Әвәләү: «Зур һәм кечкенә очкычлар» | Биремгә карап төзүне үзгәртергә өйрәтү.Һава транспорты әвәләргә өйрәтүне ныгыту(очкыч).Әвәләү ысуллары турындагы күзаллауларын ныгыту.Эшнең нәтиҗәсен күрүдән шатлану хисләре уяту. | Табышмак уку, уен аркылы проблемалы ситуация тудырып, әвәләү ысулларын искә төшерү. | Балчык яисә пластилин, поднос, әвәләү өчен такта, тастымал, өстәмә материаллар, куян,очкыч уенчыгы, кечкенә уенчыклар. |
| | Рәсем «Куянны Рәнҗетте-ләр» | Балаларга куян рәсеме ясарга өйрәтү. Рәсем ясау барышында анын пропорциясен саклауны ныгыту (гәүдә - зур, баш - кечерәк, койрык - кечкенә, колоак - озын)<br>Куян образын сурәтләргә һәм кәгазъ битенә урнаштырырга өйрәтү.Табигат белән кызыксыну һәм аны ярату хисләре формалаштыру. Балаларны Р. Корбан «Куянны рәнҗеттеләр» дигән шигере белән таныштыру | Нәфис сүз, индивидуаль булы-шу, мактау, тулы күрсәтмә бирү, мөстәкыйль эш, әңгәмә, бәя бирү алымнарын куллану. | А4 форматында соры битләр,иллюстрация, акбур |
